816. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 650-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен салым ташламаларының гамәлдә булу срогын төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*.......................................380

817. «Ф.Г. Шәйхиевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ...........................................................381

818. «КНИАТ» инновация-технология үзәге» сәнәгать технологияләре технопаркы» ААҖ коллективын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*..................381

819. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 654-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү турында, шулай ук, боз калынлыгы 7 сантиметрдан кимрәк булганда, су объектлары бозына чыккан һәм (яисә) транспортта чыккан өчен административ җаваплылык билгеләү хакында) алдан карау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*..................382

820. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматның ачык булуын тәэмин итү турында» 653-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ................................383

821. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 652-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (социаль яллау шартнамәләре буенча яллаучылары һәм яллаучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләре булган ятим балаларның моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яши алмавы фактын билгеләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................ 384

822. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.К. Шиһабетдинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 659-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (инвестиция эшчәнлеге субъектларына салым ташламалары бирү срогын төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................ 385

823. «С.М. Кабаковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................ 386

824. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.К. Шиһабетдинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 657-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (инвестицияле салым кредиты бирү тәртибе турындагы норманы төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* .............. 387

825. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.К. Шиһабетдинов тарафыннан кертелгән «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар

табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 658-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (оешмалар табышына салым буенча киметелгән салым ставкасын куллану хокукына ия салым түләүчеләр даирәсен киңәйтү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* .....388

826. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.К. Шиһабетдинов тарафыннан кертелгән «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 655-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (транспорт салымын түләүдән азат ителә торган салым түләүчеләр категорияләрен киңәйтү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*.....................................389

827. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.К. Шиһабетдинов тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 656-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында яңа булдырылган, сатып алынган оешма мөлкәтенә салым ташламалары бирү шартларын төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..............390

828. «Р.Г. Габдуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..................................................391

829. «Р.Р. Гайзатуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..................................................392

830. «П.М. Городковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..................................................392

831. «Г.Ә. Йосыпованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турын-

да» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....................................................393

832. «А.В. Тугановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....................................................393

833. «Г.В. Королеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ....................................................394

834. «М.М. Гыйльметдинованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..........................................394

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 697. Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен 2015 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү турында

**Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы тарафыннан<br>2014 елның 8 июлендә<br>кабул ителде**

**1 статья**

Пенсиягә «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган социаль өстәмә билгеләү максатларында 2015 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен 6310 сум итеп билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль<br>2014 елның 23 июле<br>№ 57-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 698. Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) V бүлекнең исемендә «Татарстан Республикасы милкендәге һәм» сүзләрен «Дәүләт милкендәге яисә» сүзләренә алмаштырырга;

2) $32^1$ статьяның 13 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән гражданнарга җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы уздырыла торган көнгә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча аны уздыру урыны, датасы, вакыты турында адресатка тапшырылуы хакында белдерү кәгазе булган заказлы хат, телеграмма йә, имза куйдырып, хәбәрнамә тапшыру юлы белән хәбәр ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 58-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 699. «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә «(алга таба – вәкаләтле орган)» сүзләреннән соң «, яисә аның буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренә» сүзләрен өстәргә;

2) 3 өлештә «вәкаләтле органга» сүзләреннән соң «яисә аның буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 59-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 670. «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 6 августындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 5 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) дүртенче абзацта «, хезмәтне саклау буенча инструктаж, эш урынында стажировка» сүзләрен төшереп калдырырга, «оештыра» сүзен «координацияли» сүзенә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта «, хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрүне һәм хезмәтне саклау эшләрен оештыруның хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләренә туры килүен раслауны үткәрүне оештыра» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 6 статьяның унҗиденче абзацында «компенсацияләргә» сүзен «гарантияләргә һәм компенсацияләргә» сүзләренә алмаштырырга, «авыр эшләрдә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 7 статьяда:

а) өченче өлештә «Авыр эшләр,» сүзләрен төшереп калдырырга, «компенсацияләр һәм ташламалар» сүзләрен «гарантияләр һәм компенсацияләр» сүзләренә алмаштырырга;

б) җиденче өлештә «авыр эшләрне,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 8 статьяда:

а) исемдә «Авыр эшләргә,» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) беренче өлештә «Авыр эшләрдә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 10 статьяның өченче абзацында «җитештерү объектларын төзүне һәм реконструкцияләүне проектлаганда, яңа техниканы җитештергәндә һәм гамәлгә керткәндә, яңа технологияләр һәм җиһазларны керткәндә эш урыннарына» сүзләрен «хезмәт шартларына» сүзләренә алмаштырырга;

6) 14 статьяның икенче өлешендә:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:
«хезмәтне саклау белән идарә итү системасын булдыруны һәм аның эшләвен;»;
б) өченче – тугызынчы абзацларны тиешенчә дүртенче – унынчы абзацлар дип санарга;
в) унынчы абзацны унберенче абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«хезмәт шартларын махсус бәяләү турында законнар нигезендә хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруны;»;
г) унберенче һәм уникенче абзацларны тиешенчә уникенче һәм унөченче абзацлар дип санарга;
д) унөченче абзацны ундүртенче абзац дип санарга һәм анда «һәм аларга тиешле компенсацияләр» сүзләрен «, аларга бирелә торган гарантияләр, аларга тиешле компенсацияләр» сүзләренә алмаштырырга;
е) ундүртенче – егерме өченче абзацларны тиешенчә унбишенче – егерме дүртенче абзацлар дип санарга;

7) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле бишенче өлеш өстәргә:
«Дәүләт хезмәтне саклау өлкәсендә белгечләр әзерләүне тәэмин итә.»;

8) 17 статьяның беренче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

9) 23 статьяның дүртенче өлешендә «, шул исәптән производствода бәхетсезлек очрагы алдыннан булган чорда,» сүзләрен төшереп калдырырга, «авыр эш, зарарлы һәм (яисә) хәвефле хезмәт шартларында эшләгән өчен хезмәткәрләргә компенсацияләр» сүзләрен «зарарлы һәм (яисә) хәвефле хезмәт шартларында эшләгән өчен хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр» сүзләренә алмаштырырга, «хезмәт шартлары буенча хезмәт урыннарына аттестация үткәрү сыйфатын»

сүзләрен «хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын» сүзләренә алмаштырырга, «, җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазландыру, яңа техника җитештерү һәм гамәлгә кертү, яңа технологияләрне гамәлгә кертү проектларының хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләренә туры килүен» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 60-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 671. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«9 статья. **Укучылар киеменә карата таләпләр**

1. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар, әгәр Федераль законда, әлеге статьяның 2 өлешендә башкасы билгеләнмәгән булса, укучылар киеменә карата таләпләр, шул исәптән киемнең гомуми күренешенә, төсенә, фасонына, укучыларның кием төрләренә, аерымлык билгеләренә карата таләпләр куярга һәм аны киеп йөрү кагыйдәләрен билгеләргә хо-

куклы. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың тиешле локаль норматив акты укучылар советының, ата-аналар советының, шулай ук әлеге оешма хезмәткәрләренең һәм (яисә) анда укучыларның вәкиллекле органы (булган очракта) фикерен исәпкә алып кабул ителә.

2. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең муниципаль мәгариф оешмалары укучылар киеменә карата таләпләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган үрнәк таләпләр нигезендә билгелиләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 61-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 672. «2014 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«2014 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләреннән соң «һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

2) 1 статьяда «гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләреннән соң «һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

3) кушымтада:

а) исемендә «гомуми белем бирү оешмаларында» сүзләреннән соң «һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Һөнәри белем бирү оешмаларында төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү нормативлары

| Гомуми белем баскычы | Сыйныф төре | Белем бирү профиле | Җирлек (округ)[1] | Елына бер укучыга норматив, сумнарда |
|---|---|---|---|---|
| Төп гомуми белем (белем бирүнең икенче баскычы) | Лицей, гимназия сыйныфлары | Гуманитар профиль | шәһәр | 24896 |
| | Өстәмә белем | | | 938 |

[1]Шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән, республика буйсынуындагы бюджет өлкәсе оешмалары белгечләренә авыл җирендә эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр билгеләү хокукы булган шәһәр җирлекләре өчен шәһәр җирлегендә елына бер укучыга нормативка карата 1,12 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәлдә булуы 2014 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 62-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 673. «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

1 статья

«Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10; 2010, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

1. Әлеге Законда кулланыла торган, әлеге статьяда билгеләнмәгән төшенчәләр «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» 1998 елның 8 гыйнварындагы 3-ФЗ номерлы Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

2. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) көчле тәэсир итүче матдәләр – көчле тәэсир итүче матдәләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән матдәләр;

2) агулы матдәләр – Наркотик чаралар турындагы бердәм конвенция, Психотроп матдәләр турында конвенция, Наркотик чаралар турында конвенция, көчле тәэсир итүче матдәләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлеге нигезендә наркотик чараларга, психотроп һәм көчле тәэсир итүче матдәләргә кертелмәгән, хроник агулану, психик һәм физик бәйлелек синдромы барлыкка китерергә мөмкин булган дару чаралары һәм башка матдәләр;

3) психоактив матдәләр – наркотик чаралар, психотроп, көчле тәэсир итүче һәм агулы матдәләр җыелмасы;

4) токсикомания – көчле тәэсир итүче һәм агулы матдәләрне чиктән тыш күп куллану нәтиҗәсендә барлыкка килгән авыру халәт;

5) девиантлык – социаль тәртип нормаларына каршы килә торган гамәлләр кылу;

6) социаль реабилитация – психоактив матдәләрне чиктән тыш күп куллануны туктаткан затларны ресоциализацияләүгә, аларга төзәлергә һәм һөнәри күнекмәләр алуда ярдәм күрсәтүгә, ремиссияне саклап калу өчен бу затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына психологик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы;

7) гражданнарны наркотикларга каршы торырга өйрәтү һәм тәрбияләү – наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалауның наркомания белән авыруның сәбәпләре, чагылышлары, өзлегүләре, медицина һәм социаль яктан тискәре нәтиҗәләре турында, наркотик чаралар, психотроп матдәләр куллануга җәлеп ителүгә каршы тору ысуллары хакында белем таратуга, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен алып бару күнекмәләрен булдыруга юнәлдерелгән мәҗбүри состав өлеше;

8) наркоманияне профилактикалау – наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны, наркотик бәйлелекне профилактикалау.»;

2) 3 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында «өлкәсендә» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

3) 4 статьяда:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) наркоманияне профилактикалау, наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең, аеруча балалар һәм яшьләр арасында, законсыз әйләнешенә бәйле булган хокук бозуларны профилактикалау чараларының өстенлеге, шулай ук наркотикларга каршы пропагандалауга юнәлдерелгән эшчәнлекне кызыксындыру;»;

б) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) наркоманияне профилактикалау чараларын, наркотик чараларны кулланучы затларны медик-социаль реабилитацияләү, социаль һәм хезмәт реинтеграцияләү чараларын гамәлгә ашыручы йә мондый чараларны гамәлгә ашыруда финанс ярдәме күрсәтүче оешмалар эшчәнлегенә, күрсәтелгән оешмаларның оештыру-хокукый рәвешенә карамастан, дәүләт ярдәме күрсәтү;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 9 – 11 пунктлар өстәргә:

«9) наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне медицинага кагылышсыз кулланучы затларны ачыклау буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының хокук саклау органнары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлеге;

10) наркоманияне таратуга каршы көрәшкә һәм наркомания белән авыручыларны медицина реабилитацияләве һәм социаль реабилитацияләү учреждениеләренең челтәрен үстерүгә дәүләти булмаган оешмаларны һәм гражданнарны җәлеп итү;

11) наркомания белән авыручыларны наркоманиядән дәвалануга, медицина һәм (яисә) социаль реабилитацияләүгә җәлеп итү, шулай ук табиб күрсәтмәсеннән башка наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне ара-тирә кулланучы затларны профилактикалау чараларын үтүгә җәлеп итү.»;

4) 5 статьяда:

а) исемендә «органнарының» сүзен «органының» сүзенә алмаштырырга, «учреждениеләренең» сүзен «оешмаларының» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендәге органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:»;

1 пунктта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктта «гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем мәгариф оешмаларында белем алучыларга» сүзләренә алмаштырырга, «уздыруны оештыру һәм аның» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау, мәгариф оешмалары өчен профилактика өлкәсендә белгечләр әзерләү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының югары белем мәгариф оешмаларының ректорлар советы һәм Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларының директорлар советы белән хезмәттәшлек;»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$) гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем мәгариф оешмаларында белем алучыларның наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануын, алар арасында наркоманияне һәм токсикоманияне вакытыннан элек ачыклау чараларын уздыруны тәэмин итү;»;

в) 2 өлештә:

беренче абзацта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта «гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына» сүзләрен «гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем мәгариф оешмаларында белем алучыларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны, наркоманияне вакытыннан элек ачыклау максатларында мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә белем алучыларга социаль-психологик тестлар уздыруны оештыру;»;

5 пунктта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

5) 6 статьяда:

а) исемендә «органнарының» сүзен «органының» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең беренче абзацында «Башкарма хакимиятнең» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең» сүзләренә алмаштырырга, «органнары» сүзен «органы» сүзенә алмаштырырга;

6) 7 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органының һәм медицина оешмаларының наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре»;**

б) 1 өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау, наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне медицинага кагылышсыз куллануны кисәтү һәм аңа каршы көрәш, наркомания белән авыручы затларны дәвалау һәм реабилитацияләү буенча программаларны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$) наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны вакытыннан элек ачыклау максатларында гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары, шулай ук югары белем мәгариф оешмалары укучыларына профилактик медицина тикшерүләре уздыру шартларын билгеләү;»;

в) 2 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Медицина оешмалары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:»;

7) 8 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 9 статьяда:

а) исемендә «органнарының» сүзен «органының» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең беренче абзацында «Башкарма хакимиятнең» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең»

сүзләренә алмаштырырга, «органнары» сүзен «органы» сүзенә алмаштырырга;

9) 10 статьяда:

а) исемендә «органнарының» сүзен «органының» сүзенә алмаштырырга, 1 өлешнең беренче абзацында «органнары» сүзен «органы» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «органнары» сүзен «органы» сүзенә алмаштырырга;

10) 14 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге чараларны башкаруга юнәлдерелгән республика программаларын әзерли, раслый һәм гамәлгә ашыра;»;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау, наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне медицинага кагылышсыз куллануны кисәтү һәм аңа каршы көрәш, наркомания белән авыручы затларны дәвалау һәм реабилитацияләү буенча норматив хокукый актлар кабул итә;»;

11) 15 статьяның 2 өлешендә «дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

12) 18 статьяның 1 өлешендә «дәүләт хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге башкарма органы системасының наркология учреждениеләрендәге» сүзләрен «башкарма хакимияте органы системасының наркология медицина оешмаларындагы» сүзләренә алмаштырырга;

13) 19 статьяда:

а) исемендә «Гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына медицина тикшерүе» сүзләрен «Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем мәгариф оешмаларында белем алучыларга профилактик медицина тикшерүләре» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә «Гомуми урта белем бирү учреждениеләре һәм башлангыч һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына, махсус урта һәм югары уку йортлары студентларына медицина тикшерүе» сүзләрен «Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары

белем мәгариф оешмаларында белем алучыларга профилактик медицина тикшерүләре» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге башкарма органы системасының наркология учреждениеләрендәге» сүзләрен «башкарма хакимияте органы системасының наркология медицина оешмаларындагы» сүзләренә алмаштырырга;

14) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Белем алучыларны наркотикларга каршы тәрбияләү**

1. Гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем мәгариф оешмалары белем алучыларда сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыруда, наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануның, наркоманиянең зарарлы нәтиҗәләрен, наркотикларның законсыз әйләнешенә бәйле булган хокук бозулар кылуның хокукый нәтиҗәләрен аңлатуда ярдәм күрсәтә.

2. Гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем мәгариф оешмалары наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган чараларны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый чаралар комплексларын мөстәкыйль рәвештә эшләргә һәм гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

15) 24 статьяда:

а) 1 өлештә «сәламәтлек саклау учреждениеләре» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга, «сәламәтлек саклау өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы рөхсәт иткән» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлештә «сәламәтлек саклауның наркология учреждениеләре» сүзләрен «наркология медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

16) 25 статьяда:

а) 1 өлештә «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «дәвалау учреждениеләре» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

17) 26 статьяның 2 өлешендәге икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендәге органы аларның дәвалану курсы һәм медик-социаль реабилитацияләү үткән затларны социаль реабилитацияләү буенча эшчәнлекләрен кызыксындыру буенча чаралар комплексын эшли һәм гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 63-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 674. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1[1] статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) җирле үзидарә органнарының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген.»;

2) 3.10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозу**

1. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозган өчен —

кисәтү ясала яисә гражданнарга бер меңнән алып бер мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга — дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр; юридик затларга кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр административ штраф салына.

2. Бозның калынлыгы 7 сантиметрдан кимрәк булганда, су объектлары бозына җәяүләп һәм (яисә) транспортта кергән өчен —

кисәтү ясала яисә гражданнарга бер мең биш йөз сумнан алып ике мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга — биш меңнән алып җиде мең сумга кадәр; юридик затларга илле меңнән алып җитмеш мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

3) 8.1 статьяда:

а) исемендә «Административ» сүзе алдыннан «Әлеге Кодекста каралган» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 13[1] өлеш өстәргә:

«13[1]. Әлеге статьяның 2, 5, 9 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, шушы Кодексның 2.6, 3.2, 3.4, 3.6, 3.7, 4.4 статьяларында (җирлекләр милкендәге торак булмаган фонд объектларына карата) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары (секретарьлары), шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган җирлекләрнең башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары төзи.»;

в) 14 өлештә «13» санын «13[1]» санына алмаштырырга, «беркетмәләрне» сүзеннән соң «шәһәр округларының, муниципаль районнарның» сүзләрен өстәргә;

г) 15 өлештә «14 өлешендә» сүзләрен «$13^1$, 14 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 16 өлештә «очракта,» сүзеннән соң «шәһәр округларының, муниципаль районнарның» сүзләрен өстәргә;

4) түбәндәге эчтәлекле 8.2 статья өстәргә:

«8.2 статья. **Җирле үзидарә органнарының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары**

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.4 статьясының 1 өлешендә, $19.4^1$ статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне түбәндәгеләр төзи:

1) муниципаль районнарда, шәһәр округларында – муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре, аларның беренче урынбасарлары, муниципаль районнарның, шәһәр округларының башкарма комитетларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары, шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары;

2) җирлекләрдә – җирлекләр башлыклары, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре, җирлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары (секретарьлары), шулай ук вазыйфаи бурычларына муниципаль контрольне башкару керә торган җирлекләрнең башкарма комитетларының башка вазыйфаи затлары.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 64-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 675. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән килешүләр, рәвешләр һәм тәртип буенча төзүчеләрнең үз йөкләмәләрен үтәү хакында алардан квартал саен хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтерлык (шул исәптән еллык) хисабын алу;»;

б) бишенче абзацта «нигезләмәләренең» сүзен «таләпләренең» сүзенә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацта «гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затларга Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларын, башкарма хакимиятнең күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашырырга вәкаләтле федераль органының норматив хокукый актларын бозуларны бетерү турында күрсәтмәне» сүзләрен «гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затларга Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, башкарма хакимиятнең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль органының норматив хокукый актлары таләпләрен бозуны бетерү турында күрсәтмәне» сүзләренә алмаштырырга;

г) җиденче абзацта «акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүне гамәлгә ашыручы» сүзләрен «акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче» сүзләренә алмаштырырга;

д) тугызынчы абзацта «акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы» сүзләрен «акчаларын җәлеп итүче» сүзләренә алмаштырырга;

е) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затлардан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган белешмәләрне һәм (яисә) документларны «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән вакытта алу;»;

ж) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән критерийлар нигезендә акчалары күпфатирлы йортларны төзүгә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргәннәр дип тану һәм мондый гражданнарның реестрын алып бару.»;

2) 6 статьяның 2 өлешендәге $5^1$ пунктында «төзүчене» сүзен «гражданнарның акчаларын төзелеш өчен җәлеп итүче затны» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 65-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 676. Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

«Географик объектлар исемнәре турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан географик объектларга исемнәр бирү турындагы яисә мондый географик объектларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау, кирәкле чыгымнар турында тиешле территорияләр халкына мәгълүмат бирү һәм күрсәтелгән тәкъдимнәр турында халык фикерен ачыклау тәртибен билгели.

2 статья. **Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турында тәкъдим җибәрү**

1. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимне түбәндәгеләр кертә ала:
1) Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары;

3) җирле үзидарә органнары;

4) иҗтимагый берләшмәләр;

5) юридик затлар;

6) Россия Федерациясе гражданнары.

2. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә.

3. Административ-территориаль берәмлеккә яисә торак пунктка исем бирү турындагы тәкъдим тиешенчә административ-территориаль берәмлек яисә торак пункт төзелү йә аларның үзгәртеп төзелүе (административ-территориаль берәмлекнең яисә торак пунктның үзгәртеп төзелүе тиешенчә яңа административ-территориаль берәмлек яисә яңа торак пункт төзелүгә китергән очракта) турындагы тәкъдим белән бер үк вакытта кертелә.

4. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелгәндә, түбәндәге документлар тапшырыла:

1) географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим кертү хакындагы карарның күчермәсе (күрсәтелгән тәкъдим коллегиаль орган тарафыннан кертелгәндә);

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге өлешнең 6 пунктында каралган чыгымнарның исәп-хисабы нигезле булуы турындагы нәтиҗәне үз эченә алган бәяләмәсе, шулай ук географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү буенча эшләрне финанслау өчен кирәкле Татарстан Республикасы бюджеты акчалары турында белешмәләр (географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелмәгән очракта);

3) территориясендә географик объект урнашкан муниципаль берәмлекнең (шәһәр округының яисә муниципаль районның һәм аның составына керүче җирлекнең) вәкиллекле органының географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы мәсьәлә буенча әлеге органның фикерен үз эченә алган карарының күчермәсе (географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдим тиешле муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кертелмәгән очракта);

4) географик объект урнашкан территориянең, масштабны һәм шартлы билгеләрне күрсәтеп, А3 форматында төсле вариантта карта-схемасы;

5) аңлатма язуы, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) географик объектның төре;

б) территориясендә географик объект урнашкан административ территориаль берәмлекнең, шәһәрнең яисә авыл җирлегенең исемен күрсәтеп, географик объектның урнашкан урыны, географик объектның урнашкан урынын билгеләү өчен кирәкле географик координаталар йә башка ориентирлар;

в) географик объектка исем бирү йә аның исемен үзгәртү зарурлыгын нигезләү;

г) географик объектның тәкъдим ителә торган исеме һәм аны нигезләү, шул исәптән тәкъдим ителә торган исемнең татар һәм (яисә) Татарстан Республикасы халыкларының башка телендә язылу үрнәге (әгәр ул булса һәм рус телендәге язмасыннан аерылса), шулай ук географик объектның гамәлдәге исеме турында белешмәләр (географик объект исемен үзгәртү турында тәкъдим кертелгәндә);

д) географик объектның җирле халык арасында гамәлдә йөри торган исемнәре турында белешмәләр (булган очракта);

е) административ-территориаль берәмлек, Татарстан Республикасы чикләрендә тиңдәш географик объектларның бер исемдәге һәм бер тамырлы исемнәре турында белешмәләр;

ж) географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турында тәкъдим керткән дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, иҗтимагый берләшмә, юридик зат яисә Россия Федерациясе гражданы (алга таба – тәкъдим кертүче субъект) турында белешмәләр;

з) физик затның тормышы һәм эшчәнлеге турында кыскача тарихи белешмә, әлеге географик объект исеме буларак физик зат исеме тәкъдим ителгән очракта;

6) географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү өчен кирәкле чыгымнарның исәп-хисабы;

7) географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимнәргә экспертиза үткәрү өчен федераль законнар нигезендә кирәкле башка документлар, материаллар һәм белешмәләр.

5. Әлеге статьяның 4 өлешендә каралган документлар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә кертелә, моңа тиешле органда эш башкару буенча билгеләнгән кагыйдәләр нигездә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә кабул ителә (рәсмиләштерелә) торган карарлар, бәяләмәләр һәм башка документлар керми. Бу очракта тәкъдим кертүче субъект күрсәтелгән документны, аның Татарстан Республикасының икенче дәүләт теленә тәрҗемәсен кушып, оригинал телендә тапшыра.

6. Тәкъдим кертүче субъект кертелгән тәкъдим буенча тиешле территорияләрдәге халыкның фикерен алдан ачыклауны раслый торган документлар (гражданнардан сораштыруның, гражданнар җыелышлары, конференцияләре карарларының, халыкның үз фикерен башкача белдерү рәвешләренең, шул исәптән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгәннәрнең дә, нәтиҗәләре), шулай ук кертелгән тәкъдимгә кагылышлы белешмә, мәгълүмат һәм башка материаллар тапшырырга хокуклы.

7. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турында әлеге статья таләпләренә туры килми торган тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советында каралырга тиеш түгел һәм тәкъдим кертүче субъектка кире кайтарыла.

3 статья. **Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү өчен кирәкле чыгымнар турында тиешле территорияләр халкына мәгълүмат бирү**

Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү өчен кирәкле чыгымнар турында тиешле территорияләр халкына мәгълүмат бирү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

4 статья. **Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдим хакында тиешле территорияләрдәге халыкның фикерен ачыклау**

1. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турында кергән тәкъдим хакында тиешле территорияләрдәге халыкның фикерен ачыклау гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Гавами тыңлаулар үткәрү турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитеты тарафыннан кабул ителә.

2. Гавами тыңлаулар үз территориясендә тиешле географик объект урнашкан җирлектә (шәһәр округында) үткәрелә.

3. Гавами тыңлауларга тикшерү өчен чыгарыла торган мәсьәлә турында, шулай ук аларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турындагы хәбәр гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштырыла, шулай ук «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарыла.

4. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитеты тарафыннан төзелә торган эшче төркем тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Гавами тыңлауларда үз территориясендә тиешле географик объект урнашкан җирлекнең (шәһәр округының) барлык халкы катнашырга хокуклы.

6. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелә, анда географик объектка исем бирү яисә географик объект исемен үзгәртү мәсьәләсе буенча халыкның гавами тыңлаулар барышында ачыкланган фикере күрсәтелә. Беркетмәгә эшче төркем җитәкчесе имза сала, һәм ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитетына тапшырыла.

7. Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 10 көн эчендә гавами тыңлаулар беркетмәсе «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштырыла.

5 статья. **Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне карау**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне әлеге Законның 4 статьясы нигезендә ачыкланган халык фикерен исәпкә алып карый.

2. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы күрсәтелгән тәкъдимне хуплау яисә аны кире кагу турында карар кабул итә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге статьяның 2 өлешендә каралган карары тәкъдим кертүче субъектка җибәрелә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштырыла.

4. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан хупланган тәкъдим, күрсәтелгән тәкъдимне нигезли торган документлар һәм кирәкле чыгымнарның исәп-хисабы географик объектка исем бирү яисә географик объектның исе-

мен үзгәртү турында мәсьәләне карау өчен федераль законнар нигезендә федераль дәүләт хакимияте органына җибәрелә.

5. Федераль дәүләт хакимияте органы географик объектка исем бирүдән яисә географик объектның исемен үзгәртүдән баш тарткан очракта, шул исәптән географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимгә тискәре бәяләмә булган очракта, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитеты географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү мәсьәләсе буенча документларны һәм материалларны тәкъдим кертүче тиешле субъектка җибәрә.

6. Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кабат кертү һәм карау күрсәтелгән тәкъдимне кертү һәм карау өчен әлеге Законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 66-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 677. Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014,

№ 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 4 өлешендә «агып төшүче сулардагы һәм (яисә) дренаж суларындагы» сүзләрен «агып төшүче сулардагы, шул исәптән дренаж суларындагы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 42 статьяда:
а) исемдә «финанслау» сүзен «финанс белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;
б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Региональ дәрәҗәдәге объектларга дәүләт экология экспертизасы уздыруны, шул исәптән аны кабат уздыруны финанс белән тәэмин итү, заказчы дәүләт экология экспертизасы узарга тиешле документларны, федераль законнар нигезендә экология экспертизасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең экология экспертизасы өлкәсендәге вәкаләтле башкарма органы дәүләт экология экспертизасын уздыруга билгели торган чыгымнар сметасы нигезендә исәпләнгән җыемны кертү шарты белән, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;
в) 2 – 4 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 43 статьяда:
а) исемдә «финанслау» сүзен «финанс белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;
б) «финанслау» сүзен «финанс белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

4) 98 статьяда:
а) 3 өлештә «Явым-төшем сулары агып төшә торган канализация» сүзләрен «Явым-төшем суларын агызу өчен үзәкләштерелгән су чыгару системалары» сүзләренә алмаштырырга;
б) 11 өлештә «әһәмияткә ия булган» сүзләреннән соң «елганың,» сүзен өстәргә;
в) 12 өлештә «явым-төшем сулары агып төшә торган канализация» сүзләрен «явым-төшем суларын агызу өчен үзәкләштерелгән су чыгару системалары» сүзләренә алмаштырырга;
г) 13 өлештә:
1 пунктта «туфракны ашлау өчен» сүзләрен «туфракның уңдырышлылыгын көйләү максатларында» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «корткычларга һәм үсемлек авыруларына» сүзләрен «зарарлы организмнарга» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5 – 8 пунктлар өстәргә:

«5) автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары (моңа, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар һәм су турындагы законнар таләпләре үтәлгән шартларда, автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары портлар, суднолар төзү һәм суднолар ремонтлау оешмалары, эчке су юллары инфраструктурасы территорияләрендә урнашкан очраклар керми), транспорт чараларын техник карау һәм ремонтлау өчен файдаланыла торган техник хезмәт күрсәтү станцияләре урнаштыру, транспорт чаралары юуны гамәлгә ашыру;

6) пестицидлар һәм агрохимикатлар саклау өчен махсуслаштырылган урыннар урнаштыру, пестицидлар һәм агрохимикатлар куллану;

7) агып төшүче суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

8) гомумтаралган файдалы казылмалар разведкалау һәм чыгару (моңа гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгаруны файдалы казылмаларның башка төрләрен разведкалау һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар үзләренә тау бүлемтекләренең җир асты байлыклары һәм (яисә) геологик бүлемтекләрнең җир асты байлыклары турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән чикләрдә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19[1] статьясы нигезендә расланган техник проектка нигезләнеп гамәлгә ашырган очраклар керми).»;

д) 14 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Су саклау зоналары чикләрендә хуҗалык объектларын һәм башка объектларны проектлау, төзү, реконструкцияләү, кулланылышка кертү, алардан файдалану, мондый объектларны су турындагы законнар һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә су объектларын пычранудан, чүпләнүдән, ләм утырудан һәм сулыкларны саегудан саклауны тәэмин итә торган корылмалар белән җиһазландыру шарты белән, рөхсәт ителә. Су объектын пычранудан, чүпләнүдән, ләм утырудан һәм сулыкларны саегудан саклауны тәэмин итә торган корылма төрен сайлап алу әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән пычраткыч матдәләр, башка матдәләр һәм микроорганизмнар агызуның рөхсәт ителә торган нормативларын үтәү зарурлыгын исәпкә алып башкарыла. Әлеге статья максатларында су объектларын пычранудан, чүпләнүдән,

ләм утырудан һәм сулыкларны саегудан саклауны тәэмин итә торган корылмалар дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) үзәкләштерелгән су чыгару системалары (канализацияләр), явым-төшем суларын агызу өчен үзәкләштерелгән су чыгару системалары;

2) агып төшүче суларны (шул исәптән яңгыр суларын, кар суларын, үтеп кергән җир асты суларын, сиптерү-юу өчен тотыла торган суларны һәм дренаж суларын) үзәкләштерелгән су чыгару системаларына җибәрү (агызу) корылмалары һәм системалары, әгәр дә алар мондый суларны җыю өчен билгеләнгән булса;

3) агып төшүче суларны (шул исәптән яңгыр суларын, кар суларын, үтеп кергән җир асты суларын, сиптерү-юу өчен тотыла торган суларны һәм дренаж суларын) чистарту өчен аларны чистартуны әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар һәм су турындагы законнар таләпләре нигезендә билгеләнгән нормативлардан чыгып тәэмин итүче локаль чистарту корылмалары;

4) җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю корылмалары, шулай ук агып төшүче суларны (шул исәптән яңгыр суларын, кар суларын, үтеп кергән җир асты суларын, сиптерү-юу өчен тотыла торган суларны һәм дренаж суларын) су үткәрми торган материаллардан ясалган су җыйгычларга җибәрү (агызу) корылмалары һәм системалары.»;

е) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ өлеш өстәргә:

«$14^1$. Гражданнарның су саклау зоналары чикләрендә урнашкан һәм агып төшүче суларны чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган бакчачылык, яшелчәчелек яисә коммерциягә карамаган дача берләшмәләре территорияләренә карата аларны мондый корылмалар белән җиһазландырган һәм (яисә) әлеге статьяның 14 өлешендәге 1 пунктта күрсәтелгән системаларга тоташтырган мизгелгә кадәр әйләнә-тирә мохиткә пычраткыч матдәләр, башка матдәләр һәм микроорганизмнар чыгуны булдырмый калучы су үткәрми торган материаллардан ясалган су җыйгычлар куллану рөхсәт ителә.»;

5) 100 статьяда:

а) 1 өлештә «Экология өлкәсендәге законнар һәм халыкны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында законнар» сүзләрен «Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар һәм халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнар» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Суларның тискәре йогынтысын (су басуны, су астында калуны, су объектларының ярлары ишелүне, сазлыкка әйләнүне) булдырмый калу һәм аннан килгән зыяннарны бетерү максатларында федераль законнар нигезендә махсус саклану чаралары уздырыла.»;

в) 3 һәм 4 өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

6) 168 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 67-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 678. Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь), түбәндәге эчтәлекле $37^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«37[1] статья. **Җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләргә һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендалаучыларга, җир кишәрлекләрен төзелеш өчен бирүгә бәйле рәвештә, алардан бу җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу, шул исәптән сатып алу турында мәгълүмат бирү**

Җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләргә һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендалаучыларга, җир кишәрлекләрен төзелеш өчен бирүгә бәйле рәвештә, алардан бу җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу, шул исәптән сатып алу турында мәгълүмат бирү җир кишәрлекләрен аерып алу планлаштырылган көнгә кадәр кимендә бер ел алдан җирле үзидарә органы тарафыннан адресатка тапшырылуы турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәрү юлы белән башкарыла, хатта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) аерып алына торган җир кишәрлегендә төзеләчәк объектның исеме һәм билгеләнеше;

2) төзелеш объектын урнаштыру урынын алдан килештерү турындагы документның исеме һәм реквизитлары;

3) аерып алына торган җир кишәрлегендә төзеләчәк объектны урнаштыру күздә тотыла торган урын;

4) аерып алына торган җир кишәрлегенең мәйданы;

5) җир кишәрлеген аерып алуның килештерү өчен тәкъдим ителә торган сроклары, тәртибе һәм шартлары;

6) җир кишәрлеген төзелеш өчен бирүгә бәйле рәвештә бу җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу, шул исәптән сатып алу ихтималы турында хәбәр иткәннән соң җир кишәрлеге милекчесе, җирдән файдаланучы, җир биләүче һәм җир кишәрлеген арендалаучы җир кишәрлегендә төзелеш алып барган яисә аны башкача яхшырткан очракта, чыгымнарны һәм зыяннарны үзләре түләү куркынычы булу турында кисәтү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 68-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 679. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга;

авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә.»;

2) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Әлеге Законның $8^2$ статьясында билгеләнгән социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән органына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $8^2$ статья өстәргә:

«$8^2$ статья. **Авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга һәм авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм чаралары**

1. Торак урыннарга мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Торак

кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән инвалидларның һәм инвалид балаларның «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясындагы алтынчы өлешендә каралган өстәмә торак мәйданына хокукы булганда, торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) мондый хокукны исәпкә алып бирелә.

3. Торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне) исәпләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

4) 9 статьяның 1 пунктында «$8^1$» санын «$8^2$» санына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 23 июле
№ 69-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 680. Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Лаеш муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен түбәндәгечә үзгәртергә:

1) «Олы Кабан авыл җирлеген» һәм «Столбище авыл җирлеген» әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) «Матюшино авыл җирлеген» һәм «Орел авыл җирлеген» әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 – 9 нчы кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

# «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## <u>карта-схемасы</u>

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта



## «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Лаеш шәһәре |
| 2 | Александровка авыл җирлеге |
| 3 | Атабай авыл җирлеге |
| 4 | Олы Кабан авыл җирлеге |
| 5 | Габишев авыл җирлеге |
| 6 | Державино авыл җирлеге |
| 7 | Егорьево авыл җирлеге |
| 8 | Хәерби авыл җирлеге |
| 9 | Көек авыл җирлеге |
| 10 | Макаровка авыл җирлеге |
| 11 | Кече Елга авыл җирлеге |
| 12 | Матюшино авыл җирлеге |
| 13 | Нармонка авыл җирлеге |
| 14 | Никольский авыл җирлеге |
| 15 | Орел авыл җирлеге |
| 16 | Пәрәү авыл җирлеге |
| 17 | Комлы Кавал авыл җирлеге |
| 18 | Рождествено авыл җирлеге |
| 19 | Сокуры авыл җирлеге |
| 20 | Урта Девятово авыл җирлеге |
| 21 | Столбище авыл җирлеге |
| 22 | Татар Сараланы авыл җирлеге |
| 23 | Татар Янтыгы авыл җирлеге |
| 24 | Чырпы авыл җирлеге |

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

## «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Лаеш муниципаль районы Питрәч, Балык Бистәсе, Алексеевск, Спас, Кама Тамагы, Югары Ослан муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Лаеш, Питрәч һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Татар Янтыгы авылыннан 6,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче (56 нчы) тоташу ноктасыннан алып 400 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешне кисеп үтеп, 100 м урман массивы буенча уза, алга таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м куаклык массивы буенча бара, 750 м инеш агымы буенча өскә таба һәм 250 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба, 3,9 км төньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Янтык участок урманчылыгындагы 8, 7, 6, 9 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап, 900 м төньяк-көнчыгышка таба 5 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 1,2 км төньяк-көнбатышка таба 5 нче, 4 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба 4 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 550 м 4 нче урман кварталы буйлап уза, алга таба 100 м төньяк-көнбатышка таба урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буенча бара, сынык сызык ясап, 150 м көнбатышка таба 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча уза, алга таба 500 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,4 км урман массивы буен-

ча, 300 м төньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 800 м 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча, 300 м көньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Питрәч участок урманчылыгындагы 132 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 600 м төньяк-көнбатышка таба 132 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 4,0 км төньякка таба 132, 131, 135 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, 300 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 4,7 км төньякка таба 135, 134, 133, 126 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнбатышка таба 125 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 950 м 127 нче, 128 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 250 м 128 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап үтә, алга таба 900 м 128 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 400 м 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 350 м 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 200 м 129 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км төньякка таба 129 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 30 м 180 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча уза, алга таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м 180 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буенча, 250 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м куаклык массивы буенча Мишә елгасының сул ярына кадәр бара, аннары 20 м төньяк-көнбатышка таба Мишә елгасы буенча һәм 350 м аның агымы буенча өскә таба уза, 40 м төньяк-көнбатышка таба әлеге елга буенча аның уң ярына кадәр бара, сынык сызык ясап, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м көньяк-көнбатышка таба куаклык массивы буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буенча, 350 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м көньяк-көнбатышка таба урман массивы буенча, 350 м төньяк-көнбатышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет

учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 110 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м 110 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 1,0 км 97 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м төньякка таба урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 100 м 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча бара, шуннан соң 350 м урман полосасының көнбатыш чиге һәм 100 м төньяк-көнбатышка таба көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буенча, 200 м урман полосасы буенча, 200 м урман массивының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивы буенча, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м куаклык массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м куаклык массивының көньяк-көнбатыш чиге буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 50 м көньяк-көнбатышка таба урман массивы буенча, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Лаеш, Питрәч муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Олы Кабан авылыннан 6,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 9 нчы (45 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 35 нче (56 нчы) тоташу ноктасыннан алып 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м куаклык массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 50 м әлеге массив буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, алга таба 150 м әлеге инеш агымы буенча аска таба аның Брысса елгасына койган урынына кадәр бара, аннары 450 м әлеге елга агымы буенча буага кадәр уза, 350 м буаның уң яры буйлап плотинага кадәр бара, 20 м төньяк-көнчыгышка таба буа плотинасының көньяк-көнбатыш чиге буенча уза, алга таба 1,5 км Брысса елгасы агымы буенча аска таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м куаклык массивы буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 700 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 3,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап бара, аннары 50 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасы буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 450 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Янтык участок урманчылыгындагы 48 нче, 49 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 100 м 49 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 400 м 49 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба 49 нчы, 52 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 100 м көньяк-көнбатышка таба 51 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м үзәнлектәге сазлык буйлап бара, сынык сызык ясап, 5,6 км көньяк-көнбатышка таба 51, 54, 53, 56, 57, 58 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 200 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м урман утыртмаларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман массивы буйлап, сынык сызык ясап, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, инешләрне кисеп үтеп, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 2,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км 62 нче урман карталы буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 62 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м 62 нче, 63 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба 63, 65, 68, 69 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, 2,1 км әлеге инеш агымы буенча аска таба аның Шуранка елгасына койган урынына кадәр бара, аннары 100 м әлеге елга агымы буенча өскә таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба яр буе куаклык массивы буйлап уза, алга таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының төньяк-

көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Казан – Оренбург» – Балык Бистәсе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 1,0 км урман полосасы буйлап һәм 900 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 2,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м 75 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 500 м 78 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнчыгышка таба 78 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м 78 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көнчыгышка таба 79 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 100 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнбатышка таба 79 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба 79 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнчыгышка таба 79 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 250 м Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Лаеш, Балык Бистәсе һәм Алексеевск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шуран авылыннан 7,8 км көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 429494,20, Y = 1358656,60 координаталы 33 нче (57 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Лаеш, Алексеевск һәм Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шуран авылыннан 17,4 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 51 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 33 нче (57 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 51 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 26,0 км көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Лаеш, Спас һәм Кама Тамагы муниципаль

районнары чикләре тоташкан урында Атабай авылыннан 9,0 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 50 нче (33 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 50 нче (33 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Лаеш, Кама Тамагы һәм Югары Ослан муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Яңа Поляна авылыннан 5,9 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 7 нче (42 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Лаеш, Югары Ослан муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Матюшино авылыннан 5,7 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (41 нче) тоташу ноктасыннан алып көньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 7 нче (42 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы (45 нче) тоташу ноктасыннан алып 6,14 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны, юл буе урман полосасын һәм Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м көньяк-көнбатышка таба «Казан» аэропорты юлы» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 60 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 420 м төньякка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 515 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 75 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 360 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 90 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 395 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 135 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 910 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 370 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 230 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 170 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,15 км көньяк-көнчыгышка таба, 780 м көньяк-көнбатышка таба, 735 м төньяк-көнбатышка таба, 355 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 665 м төньякка таба бара, аннары 575 м төньяк-

көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 190 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 205 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 220 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 910 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 275 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Боровое Матюшино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чигенә кадәр бара, 205 м төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 550 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, 155 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 350 м төньяк-көнбатышка таба, 80 м урман массивы буенча, 105 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 90 м урман массивы буйлап бара, аннары 595 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 105 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 125 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 75 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 385 м урман массивының төньяк чиге буйлап, 185 м чокыр төбе буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 340 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап һәм 25 м төньяк-көнбатышка таба уза, алга таба 25 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 265 м сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 15 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 10 м чокыр буенча кибеп баручы инешкә кадәр уза, 1,71 км әлеге инеш агымы буенча аска таба, сынык сызык ясап, 270 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 135 м көньяк-көнчыгышка таба ишелмәләр буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 985 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 3,07 км чокыр төбе буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнчыгышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 365 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 35 м көньяк-көнчыгышка таба, Казан станциясе – аэропорт тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 10 м көньяк-көнбатышка таба, 525 м көньяк-көнчыгышка таба, 15 м төньяк-көнчыгышка таба, 735 м көньяк-көнчыгышка таба Казан станциясе – аэропорт тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 125 м көньякка таба күмәк бакчаларның көнчыгыш чиге буйлап, 700 м Казан станциясе – аэропорт тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап

уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,07 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 820 м Казан – Столбище автомобиль юлы буйлап бара, аннары 200 м төньяк-көнбатышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 111 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,08 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 60 м 96 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 305 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 405 м 96 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 280 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 275 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 810 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 10 м урман массивы буйлап бара, алга таба 2,61 км 48, 52, 51, 53 нче урман кварталлары буйлап һәм, сынык сызык ясап, 120 м көнбатышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 215 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 280 м төньяк-көнбатышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 285 м төньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 640 м төньяк-көнбатышка таба 49 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,04 км көньяк-көнчыгышка таба Казан – Боровое Матюшино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап бара, 20 м көньякка таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 590 м 61 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 95 м үзәнлектәге сазлык буйлап уза, 115 м 61 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 465 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 360 м 61 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 400 м 62 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 45 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 355 м 62 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге чиге буйлап, сынык сызык ясап, 365 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м көньяк-көнчыгышка таба 63 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 105 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 95 м 63 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 80 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 75 м 63 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 60 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 530 м көньякка таба Казан шәһәрен Лаеш муниципаль районының Орел авылы белән тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 250 м көнбатышка таба һәм 50 м көньякка

таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 205 м урман массивының төньяк чиге буйлап, 20 м көньякка таба урман массивы буйлап, сынык сызык ясап, 165 м көнбатышка таба күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап, 30 м төньяк-көнчыгышка таба күмәк бакчалар буйлап, 950 м күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 160 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 195 м төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге һәм 220 м көнбатышка таба төньяк чиге буйлап, 190 м 64 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 240 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Матюшино участок урманчылыгындагы 62 нче, 58 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 515 м көньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап, 305 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 860 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Столбище участок урманчылыгындагы 62 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,88 км төньякка таба 60 нчы, 59 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 790 м көньяк-көнбатышка таба 59 нчы урман кварталы буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,03 км төньяк-көнбатышка таба 59 нчы, 49 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге һәм 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,64 км төньякка таба 49, 44, 41 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, 400 м көньяк-көнбатышка таба «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Матюшино участок урманчылыгындагы 13 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 490 м төньяк-көнбатышка таба 13 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, 160 м 11 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба 12 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм, сынык сызык ясап, 1,34 км 94 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 175 м төньякка таба Казан – Боровое Матюшино автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 380 м төньяк-көнбатышка таба 94 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 210 м 5 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба 5 нче урман кварталы буйлап, 435 м төньяк-көнбатышка таба 12 нче урман кварталының

төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 530 м көньяк-көнбатышка таба 11 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 650 м көнбатышка таба 10 нчы урман кварталының төньяк чиге һәм 645 м көньяк-көнбатышка таба төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 440 м төньяк-көнбатышка таба 7 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 1,55 км көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы култыгы яры буенча, аны ике тапкыр кисеп үтеп, 1,55 км көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 1 нче (41 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта

## Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Александровка, Көек, Макаровка, Кече Елга, Рождествено, Чырпы авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Спас муниципаль районнары белән чиктәш.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Чырпы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Чырпы һәм Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Александровка поселогыннан 3,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м көньяк-көнчыгышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 650 м көньякка таба көнчыгыш чиге буйлап, Лаеш — Чырпы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп

үтеп, 61 нче урман кварталы буйлап 900 м көньякка таба, 500 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 400 м, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 950 м көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м сазлык буйлап бара, 200 м 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м сазлык буйлап һәм 100 м сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр бара, 7,6 км әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Чырпы һәм Кече Елга авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Полянка авылыннан 3,9 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 429951,48, Y = 1344614,99 координаталы 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Кече Елга авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 53 нче тоташу ноктасыннан алып 7,3 км көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Кече Елга авыл җирлеге һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Шуран авылыннан 10,6 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 423797,64, Y = 1340636,66 координаталы 52 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 52 нче тоташу ноктасыннан алып Лаеш муниципаль районы чиге буйлап «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Алексеевск һәм Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шуран авылыннан 17,4 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 51 нче (32 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 51 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып Лаеш муниципаль районы чиге буйлап «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Атабай, Макаровка авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Атабай авылыннан 5,8 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 49 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Макаровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Лаеш шәһәре» муници-

паль берәмлеге, Макаровка һәм Рождествено авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташкирмән авылыннан 4,8 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып 13,1 км көньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 49 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Рождествено авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Рождествено һәм Көек авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яушыек авылыннан 3,0 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 434142,25, Y = 1323682,06 координаталы 40 нчы тоташу ноктасыннан алып 5,4 км көньякка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 41 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Көек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Көек һәм Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Александровка поселогыннан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып 2,6 км көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 41 нче, 40 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, алга таба 350 м көньякка таба 40 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 350 м 40 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап 250 м көньякка таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк чиге буйлап 500 м көнчыгышка таба уза, алга таба 600 м көньяк-көнчыгышка таба 54 нче, 62 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба 62 нче, 69 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, алга таба 100 м көньякка таба һәм 150 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Лаеш – Яушыек автомобиль юлына һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 1,5 км 69 нчы, 74 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр уза, аннары 2,8 км төньяк-көнбатышка таба әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Александровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан

алып 3,4 км көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 52, 51, 50, 49 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба «Лаеш шәһәренә керү юлы» автомобиль юлы буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 116 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 2,9 км 43 нче, 42 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 4 нче кушымта

## Лаеш муниципаль районының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Александровка авыл җирлеге «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Егорьево, Державино, Көек, Урта Девятово һәм Чырпы авыл җирлекләре белән чиктәш.

Александровка авыл җирлеге чиге Урта Девятово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Александровка, Урта Девятово һәм Державино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Девятово авылыннан 1,2 км көнбатышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып 6,6 км көньяк-көнчыгышка таба Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Александровка, Урта Девятово һәм Чырпы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Смолдеярово авылыннан 750 м көньякта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Александровка авыл җирлеге чиге Чырпы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып 3,9 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 38 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 38 нче урман кварталы буйлап һәм 350 м әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 30 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 38 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 250 м кабат төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м һәм 40 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,0 км 55 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 550 м төньяк-көнбатышка таба 35 нче, 37 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнбатышка таба 37 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап һәм 1,1 км 46 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 750 м көньяк-көнчыгышка таба 47 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Александровка, Чырпы авыл җирлекләре һәм «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Александровка поселогыннан 3,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Александровка авыл җирлеге чиге «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып 3,4 км көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 52, 51, 50, 49 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба «Лаеш шәһәренә керү юлы» автомобиль юлы буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 116 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 2,9 км 43 нче, 42 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Көек һәм Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Александровка поселогыннан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Александровка авыл җирлеге чиге Көек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Александровка, Көек һәм Егорьево авыл

«Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 27 нче кушымта

## Лаеш муниципаль районының «Чырпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Чырпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чырпы авыл җирлеге «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Александровка, Кече Елга, Урта Девятово авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш.

Чырпы авыл җирлеге чиге Александровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Александровка, Урта Девятово һәм Чырпы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Смолдеярово авылыннан 750 м көньякта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып, 3,9 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгында-

гы 38 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 38 нче урман кварталы буйлап һәм 350 м әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 30 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 38 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 250 м кабат төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м һәм 40 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,0 км 55 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 550 м төньяк-көнбатышка таба 35 нче, 37 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнбатышка таба 37 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап һәм 1,1 км 46 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 750 м көньяк-көнчыгышка таба 47 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Александровка, Чырпы авыл җирлекләре һәм «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Александровка поселогыннан 3,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чырпы авыл җирлеге чиге Урта Девятово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып, 1,2 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба аңа башка кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, 450 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 350 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Янтык участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 40 м чокырның көнбатыш кырые буйлап инешкә кадәр уза, 250 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба бара, алга таба 150 м төньяк-көнчыгышка таба чокыр төбе буенча уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,5 км әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 200 м 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Брысса елгасына

кадәр бара, 400 м әлеге елга агымы буенча өскә таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр, аның чокырлы сул ярын кисеп үтеп, 1,0 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк-көнчыгышка таба, инешнең чокырлы уң ярын кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнчыгышка таба бара, 400 м 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 550 м 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 30 м 60 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 550 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге урман кварталы буйлап бара, аннары 250 м төньяк-көнчыгышка таба 60 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Емельяново авылын Меретәк авылы белән тоташтыручы профильле автомобиль юлына кадәр уза, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап бара, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Урта Девятово, Чырпы авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Меретәк авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 55 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чырпы авыл җирлеге чиге Балык Бистәсе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 55 нче тоташу ноктасыннан алып, Лаеш муниципаль районы чиге буйлап Чырпы, Кече Елга авыл җирлекләре һәм Балык Бистәсе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Меретәк авылыннан 550 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чырпы авыл җирлеге чиге Кече Елга авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 54 нче тоташу ноктасыннан алып, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Янтык участок урманчылыгындагы 64 нче, 66 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 550 м көньяк-көнбатышка таба уза, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап,

Имән Кискә – Меретәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м 61 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Имән Кискә – Меретәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге һәм 200 м көнбатышка таба көньяк чиге буйлап, 300 м урман массивы буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, 650 м әлеге инеш агымы буенча аска таба уза, аннары 700 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 150 м көнчыгышка таба 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көнчыгышка таба, 400 м көньякка таба, урман массивын кисеп үтеп, 250 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 800 м 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньяк-көнбатышка таба, 200 м көнчыгышка таба, 250 м көньякка таба, 950 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, култыкны һәм чокырлы ярны кисеп үтеп, 3,1 км әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап Кече Елга, Чырпы авыл җирлекләре һәм «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Полянка авылыннан 3,9 км көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 429951,48, Y = 1344614,99 координаталы 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чырпы авыл җирлеге чиге «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып, 650 м көньяк-көнчыгышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Лаеш участок урманчылыгындагы 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 650 м көньякка таба көнчыгыш чиге буйлап, Лаеш – Чырпы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 61 нче урман кварталы буйлап 900 м көньякка таба, 500 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 600 м, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 950 м көньяк-көнчыгышка таба 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м сазлык буйлап бара, 200 м 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 50 м 68 нче урман кварталының

төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м сазлык буйлап һәм 100 м сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Куйбышев сусаклагычы ярына кадәр бара, 7,6 км әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 70-ТРЗ

Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Лаеш муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Столбище авыл җирлегенең һәм Олы Кабан авыл җирлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге территориясе составына кертелә торган Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге территориясе

Муниципаль берәмлекләр чикләренең үзгәрешләр исәпкә алынган
**карта-схемасы**

Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 681. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.1 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;
2) 4.2 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;
3) 7.5 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;
4) 8.1 статьяда:
а) 1 өлештә «7.5 – 7.7» саннарын «7.6» саннарына алмаштырырга;
б) 14 өлештә «4.2,» саннарын төшереп калдырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10), «4.2,» саннарын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Административ хокук бозган өчен салына торган акчалата түләтүне белдерү алымын үзгәртү өлешендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 7 ноябрендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 19 һәм 20 пунктлары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 3; 2013, № 10);

2) «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1);

3) «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 18 июнендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 13, 14, 21 пунктлары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш), № 10).

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 71-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 682. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1(1); 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш), «биш» сүзен «ун» сүзенә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 72-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**683. «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы беренче өлешенең беренче җөмләсенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 1; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 4) «яисә «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның беренче өлешенә «яисә «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару)» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:

а) беренче өлештә «рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш» сүзләре алдыннан «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында» сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлештә «рәсми рәвештә бастырып чыгарыла» сүзләре алдыннан «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:

«Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) рәсми бастырып чыгару аларга имза салган көннән 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 6 статьяның беренче һәм өченче өлешләрендә «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында» сүзләрен төшереп калдырырга.

### 3 статья

1. Әлеге Закон 2014 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 73-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 684. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 пунктының, 18 статьясындагы 2 пунктының, 53[1] статьясындагы 2 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5) гамәлдә булуын 2015 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 74-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 685. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2007, № 2 – 3, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 10), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

### «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында»

### Татарстан Республикасы Законы

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукы**

1. Татарстан Республикасында һәр граждан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә һәм халык өчен әһәмиятле булган функцияләрне гамәлгә ашыру йөкләнгән башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына (алга таба – органнар һәм вазыйфаи затлар) шәхсән яисә вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләр, моңа гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгатьләре дә керә, җибәрергә хокуклы.

2. Мөрәҗәгать итү хокукын гражданнар ирекле рәвештә һәм ихтыярый гамәлгә ашыралар. Гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашырулары башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре түләүсез карала.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында коллектив мөрәҗәгать дигәндә ике яисә аннан да күбрәк гражданның мөрәҗәгате, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгате, шулай ук митингта яисә җыелышта катнашучылар тарафыннан тавыш бирү яисә имзалар җыю юлы белән кабул ителгән мөрәҗәгать аңлашыла.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төп төшенчәләр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль закон) билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле хокукый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле хокукый мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре, федераль законнар белән җайга салына.

2. Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукын яклауга юнәлдерелгән нигезләмәләрне билгели, шул исәптән гражданнарның мөрәҗәгать итү хокукына «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән гарантияләргә өстәмә гарантияләр билгели.

2 бүлек. **Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау**

4 статья. **Гражданның язма рәвештә, электрон документ рәвешендә бәян ителгән мөрәҗәгате**

1. Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелә торган органның йә исеме һәм адресы, йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, йә тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, үз фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле адрес күрсәтелергә, шәхси имзасы һәм язылу датасы куелырга тиеш.

2. Гражданнар тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, туган телендә яисә Россия Федерациясе халыкларының үзләре белгән теләсә кайсы башка телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы Гражданнарның тәкъдимнәренә, гаризаларына, шикаятьләренә җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре файдаланыла.

3. Язмача мөрәҗәгатьтә аны җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле адрес күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы әзерләнә, кылына яисә кылынган гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яисә кылган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать тиешле компетенциясе булган дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

4. Язмача мөрәҗәгать тексты укырлык булмаган очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул карау өчен тиешле компетенциясе булган органга яисә вазыйфаи затка җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга, әгәр аның фамилиясе һәм адресы укырлык булса, мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә.

5. Органга яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булса, электрон почта адресын, җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булса, почта адресын күрсәтергә тиеш. Граждан кирәкле документларны һәм материалларны мондый мөрәҗәгатькә электрон рәвештә кушып бирергә йә күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.

6. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен бирүнең әлеге статьяда һәм «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән тәртибе белән беррәттән мөрәҗәгать органга, вазыйфаи затка телеграмма яисә факсимиль элемтә аша тапшырылырга мөмкин. Күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр язма мөрәҗәгатькә карата әлеге статьяда һәм «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

5 статья. **Мөрәҗәгатьне карауга кабул итүнең мәҗбүри булуы**

1. Органга яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре буенча кергән мөрәҗәгать мәҗбүри каралырга тиеш.

2. Мөрәҗәгатьне караучы орган яисә вазыйфаи зат, кирәк булган очракта, аны урынга барып карауны тәэмин итә ала. Мөрәҗәгатьне урынга барып карауны оештыру тәртибе, шул исәптән анда бару сроклары, органнарның норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

6 статья. **Гражданның вәкаләтләре туктатылган вазыйфаи затка адресланган мөрәҗәгатен карау**

Гражданның вәкаләтләре туктатылган вазыйфаи затка адресланган мөрәҗәгате күрсәтелгән вәкаләтләрне башкару йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан карала.

7 статья. **Язмача мөрәҗәгатьне җибәрү һәм теркәү**

1. Граждан язмача мөрәҗәгатьне компетенциясенә мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү керә торган органга яисә вазыйфаи затка турыдан-туры җибәрә.

2. Язмача мөрәҗәгать органга яисә вазыйфаи затка кергән мизгелдән өч көн эчендә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

3. Күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү бу орган яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган язмача мөрәҗәгать, теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турында хәбәр итеп, мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелә, моңа әлеге Законның 4 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрак керми.

4. Язмача мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү берничә орган яисә вазыйфаи затлар компетенциясенә кергән очракта, теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, мөрәҗәгатьнең күчермәсе тиешле органнарга яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

5. Язмача мөрәҗәгать карау өчен башка органга яисә бүтән вазыйфаи затка җибәрелгәндә, орган яисә вазыйфаи зат, кирәк булган очракта, күрсәтелгән органнардан яисә вазыйфаи заттан язмача мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында документлар һәм материаллар соратып алырга мөмкин.

6. Карарына яисә гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган органга яисә вазыйфаи затка шикаятьне карау өчен җибәрү тыела.

7. Мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү үз компетенциясенә керә торган органга яисә вазыйфаи затка шикаятьне карау өчен җибәрү әлеге статьяның 6 өлешендә каралган тыю нигезендә мөмкин булмаган очракта, тиешле карарны яисә гамәлне (гамәл кылмауны) билгеләнгән тәртиптә судка бирү хокукы булу турында аңлатып, шикаять гражданга кире җибәрелә.

## 8 статья. **Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау сроклары**

1. Органга яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре буенча кергән барлык төр индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләр язмача мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

2. Аерым очракларда, шулай ук әлеге Законның 10 статьясындагы 1 өлешендә каралган гарызнамәне юллаган очракта, орган җитәкчесе, вазыйфаи зат йә шуңа вәкаләтле зат мөрәҗәгатьне карау срогын, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга аны карау срогын озайту турында хәбәр итеп, 30 көннән дә артык булмаган вакытка озайтырга хокуклы.

3. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында гражданга җавап аның буенча тиешле карар кабул ителгән мизгелдән алып өч көн эчендә, әмма әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән сроклардан да соңга калмыйча җибәрелә.

## 9 статья. **Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле рәвештә органнарга яисә вазыйфаи затларга мәгълүм булган белешмәләрне фаш итмәү**

1. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен караганда мөрәҗәгать итүче ризалыгыннан башка аның шәхси тормышы турындагы белешмәләрне куллану һәм тарату тыела, шулай ук фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү, эшләү яисә уку урыны турындагы белешмәләрне фаш итүгә юл куелмый.

2. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне фаш итүгә юл куелмый. Компетенциясенә мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү керә торган органга яисә вазыйфаи затка язмача мөрәҗәгатьне җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне фаш итү дип саналмый.

10 статья. **Язмача дәлилләрне бирү бурычы**

1. Орган яисә вазыйфаи зат мөрәҗәгатьне караучы органның яисә вазыйфаи затның билгеләнгән тәртиптә җибәрелгән гарызнамәсе буенча мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны 15 көн эчендә тапшырырга тиеш, моңа дәүләт серен яисә федераль закон нигезендә саклануы башка серне тәшкил итә торган һәм бирүнең аерым тәртибе билгеләнгән белешмәләр булган документлар һәм материаллар керми.

2. Таләп ителә торган дәлилләрне белә торып бирми калуда гаепле вазыйфаи затлар законнар нигезендә җаваплылыкка тартыла.

11 статья. **Гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру**

1. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү органнар җитәкчеләре һәм кабул итүгә вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә.

2. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итүне оештырганда гражданнарны шәхси кабул итү тәртибенә карата «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләр исәпкә алына.

3. Кабул итү билгеле бер көннәрдә һәм сәгатьләрдә, гражданнар өчен уңайлы вакытта, кирәк булганда – кичке сәгатьләрдә, эш һәм яшәү урыны буенча үткәрелә. Органнар җитәкчеләре тарафыннан кабул итү көннәре (аена кимендә ике көн) һәм сәгатьләре дә билгеләнергә тиеш.

4. Кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итүгә әзерлек өчен җаваплы вазыйфаи затларның контакт телефоннары турындагы мәгълүмат гражданнар игътибарына массакүләм мәгълүмат чаралары һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша җиткерелә. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук органнар биналарында һәркем керә алырлык урыннарда урнаштырыла.

5. Кабул итүгә язылган һәр гражданга шәхси кабул итү карточкасы тутырыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме;

2) аның яшәү урыны адресы;

3) кабул итүне алып баручы вазыйфаи затның фамилиясе;

4) башка кирәкле белешмәләр.

6. Шәхси кабул ителгәндә граждан үзен таныклый торган документ күрсәтә.

7. Телдән бәян ителгән мөрәҗәгатьтәге фактларның һәм хәлләрнең булуы бәхәссез булса һәм аларны өстәмә тикшерү таләп ителмәсә, җавап, гражданның ризалыгы белән, кабул иткән зат тарафыннан телдән бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү карточкасына язылып куела. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап бирелә.

8. Шәхси кабул итү вакытында алынган язмача мөрәҗәгать теркәлергә тиеш, һәм ул «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда һәм әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә карала.

9. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) I, II төркем инвалидлары һәм (яисә) аларның законлы вәкилләре (ата-ананың берсе, уллыкка (кызлыкка) алучылар, опекун яисә попечитель);

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары; хәрби гамәлләр ветераннары;

3) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) кабул итүгә өч яше тулмаган балалар белән килгән гражданнар.

10. Әлеге статьяның 9 өлешендәге 1 – 4 пунктларында күрсәтелгән гражданнар шәхси кабул ителгәндә үзләренең шәхси беренче чиратта кабул ителү хокукларын раслый торган документны күрсәтәләр.

11. Органнар җитәкчеләре шәхси беренче чиратта кабул ителү хокукына ия гражданнарның өстәмә категорияләрен билгеләргә мөмкин.

12. Шәхси беренче чиратта кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.

12 статья. **Шикаять белдерү хокукы**

Үзенең тәкъдиме, гаризасы, шикаяте буенча кабул ителгән карар белән килешмәүче граждан шикаять белдерелә торган ка-

рарны кабул иткән орган яисә вазыйфаи зат турыдан-туры буйсына торган органга, яисә вазыйфаи затка, яисә судка шушы карарга карата шикаять белдерергә хокуклы.

13 статья. **Законнарны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр**

1. Гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән закон чыгару инициативасы хокукына ия барлык субъектларга Татарстан Республикасы

законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итә алалар.

2. Законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан өйрәнелә, гомумиләштерелә, карала һәм закон проектларын әзерләгәндә яисә закон проектлары эшләренең планнарын төзегәндә исәпкә алынырга мөмкин.

14 статья. **Органның һәм вазыйфаи затның гаризаны карау бурычлары**

Гаризада күтәрелгән мәсьәләләрне карау үз компетенциясенә керә торган орган һәм вазыйфаи зат түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

1) гаризаны законнарда билгеләнгән срокларда асылы буенча карарга;

2) гражданның гаризасы буенча элек кабул ителгән карарларның үтәлешен исәпкә алырга;

3) нигезләнгән карар кабул итәргә һәм аның үтәлешен тәэмин итәргә;

4) гариза биргән гражданга гаризаны карау нәтиҗәләре һәм аның буенча кабул ителгән карар турында законнарда билгеләнгән срокта хәбәр итәргә;

5) гаризада бәян ителгән таләпләр канәгатьләндерелмәгән очракта, гариза биргән гражданга баш тартуның сәбәпләрен язма рәвештә җиткерергә, шулай ук гариза буенча кабул ителгән карарга шикаять бирергә мөмкин булган органны яисә вазыйфаи затны күрсәтергә.

15 статья. **Мөрәҗәгатьне караганда гражданның хокуклары**

Орган яисә вазыйфаи зат мөрәҗәгатьне караганда граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

1) мөрәҗәгатьне тикшерүче затка үзенең дәлилләрен шәхсән бәян итәргә;

2) органның тиешле структур бүлекчәсендә яисә тиешле вазыйфаи заттан язмача мөрәҗәгатьне теркәү турында, шулай ук аны карау сроклары хакында телдән (шул исәптән телефон аша) яисә электрон рәвештә мәгълүмат алырга;

3) мөрәҗәгатьне кабул иткән органның вәкаләтле заты (вазыйфаи заты) тарафыннан мөрәҗәгатьнең граждан алып килгән икенче нөсхәсендә, датаны, фамилияне һәм инициалларны күрсәтеп, имза салу юлы белән язмача мөрәҗәгатьне кабул итү фактын таныклауга;

4) өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга йә аларны соратып алу турында үтенеч белән, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итәргә;

5) башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаса һәм мөрәҗәгатьне карауга кагыла торган материалларда һәм документларда дәүләт серен яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр булмаса, күрсәтелгән документлар һәм материаллар белән танышырга;

6) мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап алырга, моңа «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән очраклар керми, язмача мөрәҗәгатьне анда күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итү үз компетенциясенә керә торган органга яисә вазыйфаи затка җибәрү турында хәбәр алырга;

7) мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга карата яисә мөрәҗәгатьне карауга бәйле административ һәм (яисә) суд тәртибендә гамәлләр кылуга (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә шикаять бирергә;

8) мөрәҗәгатьне карауны туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

9) мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга шикаять бирергә;

10) вәкил хезмәтләреннән файдаланырга;

11) органның яисә вазыйфаи затның мөрәҗәгатьне караганда законсыз гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында китерелгән чыгымнарны законнарда билгеләнгән тәртиптә каплауга һәм әхлакый зыянны компенсацияләүгә.

### 16 статья. **Органның яисә вазыйфаи затның шикаятьне карау бурычлары**

Компетенциясенә тиешле шикаятьне карау керә торган орган яисә вазыйфаи зат түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) шикаятьне кабул итәргә һәм теркәргә;

2) шикаятьне законнарда билгеләнгән срокта асылы буенча карарга, шикаятьтә китерелгән барлык дәлилләрне һәм фактларны объектив һәм вакытында тикшерергә;

3) кирәк булган очракта мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны башка органнардан һәм бүтән вазыйфаи затлардан, моңа судлар, сорау алу органнары һәм алдан тикшерү органнары керми, шул исәптән электрон рәвештә соратып алырга, шулай ук вазыйфаи затлардан аңлатмалар таләп итәргә, шаһитлар һәм экспертлар чакырырга;

4) шикаять буенча дәлилләнгән һәм әлеге Законга нигезләнгән карар кабул итәргә һәм аның реаль үтәлешен тәэмин итәргә;

5) шикаятьне карау нәтиҗәләре һәм аның буенча кабул ителгән карар турында законнарда билгеләнгән срокта гражданга, аның белән килештереп, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә телдән хәбәр итәргә.

### 17 статья. **Шикаять буенча карар**

Шикаять буенча карарда аның нигезенә салынган мотивлар һәм фактлар, законның яисә бүтән норматив хокукый актның конкрет статьясына таяну; кирәк очракларда – шикаять белдерелә торган карарны юкка чыгару яисә үзгәртү турында күрсәтү, кабул ителгән карарны үтәү срогы; законсыз карар кабул иткән яисә законсыз гамәл кылган (гамәл кылмаган) вазыйфаи затны законнарда билгеләнгән җаваплылыкка тартуның кирәклеге турында күрсәтү, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе булырга тиеш.

### 18 статья. **Шикаять буенча карар кабул итү нәтиҗәләре**

1. Шикаять тулысынча яисә өлешчә канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, шикаять буенча карар чыгарган орган яисә вазыйфаи зат гражданның бозылган хокукын торгызу буенча кирәкле чаралар күрергә, шулай ук гражданның үтенече буенча кабул ителгән карар турында кызыксынучы затларга мәгълүмат бирергә тиеш.

2. Дөрес булмаган яисә гражданга яла ягарлык белешмәләр массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылган очракта, шул белешмәләрне биргән орган яисә вазыйфаи зат законнарда билгеләнгән тәртиптә аларны кире кагуны бастырып чыгару чараларын күрергә тиеш.

### 19 статья. Органнарның «турыдан-туры элемтә» һәм «мөһим элемтә» телефоннары буенча кабул ителгән граждannar мөрәҗәгатьләрен карау

1. Органнар үз эшчәнлекләре турында гражданнарның мәгълүмат алуга хокукларын тәэмин итү максатларында, шулай ук гражданнарның мөрәҗәгатьләрен кабул итү өчен «турыдан-туры элемтәләр» һәм «мөһим элемтәләр» эшен оештырырга мөмкин.

2. Органнарның «турыдан-туры элемтә» һәм «мөһим элемтә» телефоннары аша кабул ителгән мөрәҗәгатьләр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законда һәм әлеге Законда билгеләнгән срокларда теркәлергә тиеш.

3. Органның гражданнар мөрәҗәгатьләрен «турыдан-туры элемтә» һәм «мөһим элемтә» телефоннары аша кабул итәргә вәкаләтле вазыйфаи заты гражданның мөрәҗәгатен терки һәм, мөрәҗәгать итүченең контакт телефонын һәм (яисә) электрон почта адресын (булган очракта), сорауның асылын, мөрәҗәгать кабул ителү датасын һәм вакытын күрсәтеп, мөрәҗәгатьнең электрон карточкасын булдыра.

4. Электрон карточкадагы белешмәләр мөрәҗәгатьтә күтәрелгән сорауларны хәл итү компетенцияләренә керә торган тиешле органнарга җибәрелә.

5. «Турыдан-туры элемтәләр» һәм «мөһим элемтәләр» эше органнар кабул итә торган норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 20 статья. Гражданнарның күмәк мөрәҗәгатькә язмача җавап алуга хокукларына өстәмә гарантияләр

1. Гражданнарның күмәк мөрәҗәгатенә язмача җавап мөрәҗәгатьтә җавап җибәрелә торган затка яисә мөрәҗәгатькә имза салган гражданнар коллективы вәкиле буларак күрсәтелгән затка җибәрелә.

2. Күмәк мөрәҗәгатьтә җавап җибәрелергә тиешле зат билгеләнмәгән булса, җавап мөрәҗәгать итүчеләр (имза салу-

чылар) исемлегендә үз яшәү урыны адресын күрсәткән беренче гражданга җибәрелә.

3. Күмәк мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турында үтенеч мөрәҗәгать итүче (имза салучы) затларның берничәсе тарафыннан белдерелгән очракта, җавапның күчермәсе үзләре күрсәткән адреслар буенча аларның һәрберсенә җибәрелә.

### 21 статья. **Коррупциячел фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау**

1. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гражданнар коррупциячел фактлар буенча мөрәҗәгатьләрен органнарга җибәрергә хокуклы.

2. Гражданнарның коррупциячел фактлар буенча мөрәҗәгатьләре коррупция һәм янау, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, хезмәт урынында үз-үзеңне тоту таләпләрен бозу, шулай ук вазыйфаи хәленнән явыз ниятләрдә файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылу фактлары турында белешмәләрне үз эченә ала.

3. Кергән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган гамәлләр турында, шулай ук аны әзерли, кыла һәм кылган зат хакында белешмәләр булганда, мондый мөрәҗәгать, компетенцияләренә карап, хокук саклау органнарына җибәрелә.

4. Гражданнарның коррупциячел фактлар буенча мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар хезмәттәге мәгълүматның һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә сакланышы өчен билгеләнгән тәртиптә персональ җаваплылыкка ия була.

5. Гражданнарның коррупциячел фактлар буенча мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе органнарның норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

### 22 статья. **Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык**

Әлеге Законны бозуда гаепле затлар законнарда каралган тәртиптә җаваплы булалар.

3 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

23 статья. **Әлеге Законның үтәлешен тикшереп тору**

1. Органнар һәм вазыйфаи затлар мөрәҗәгатьләрне карау, мөрәҗәгатьләргә язмача җаваплар җибәрү тәртибен һәм срокларын үтәүне үз компетенцияләре чикләрендә тикшереп торырга, шул исәптән ведомствога караган органнарда һәм оешмаларда гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеген, гражданнарны шәхси кабул итүне һәм урыннарга чыгып шәхси кабул итүне оештыруны, мөрәҗәгатьләр буенча элек кабул иткән карарларының үтәлешен тикшерүләрне үткәрергә, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны бетерү чараларын күрергә тиеш.

2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында, органнар һәм вазыйфаи затлар даими рәвештә (елына кимендә бер тапкыр) гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерергә һәм анализларга тиеш. Күрсәтелгән анализда кергән, башка адресатка җибәрелгән һәм каралган язмача мөрәҗәгатьләр, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләр турында, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре хакында, шәхси кабул ителгән гражданнарның саны турында, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар һәм урыннарга чыгып шәхси кабул итү хакында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар хакында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар (булган очракта) турында мәгълүмат булырга тиеш.

3. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибе тиешле органның норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау органнар тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына урнаштырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 75-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 686. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 12; 2003, № 8; 2005, № 10 (I өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 5 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) дүртенче абзацта «(тикшеренүләре)» сүзен төшереп калдырырга;

б) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәтне саклау таләпләре нигезендә хезмәткәрләргә санитария-көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм медицина тәэминаты күрсәтү, шулай ук эш урынында авырып киткән хезмәткәрләрне, аларга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү кирәк булган очракта, медицина оешмасына китерү;»;

в) унбишенче абзацта «(тикшеренүе)» сүзен төшереп калдырырга;

2) 12 статьяның бишенче өлешендә «(тикшеренүе)» сүзен төшереп калдырырга;

3) 14 статьяның икенче өлешендә:

а) унберенче һәм уникенче абзацларда «(тикшеренүләре)» сүзен төшереп калдырырга;

б) унҗиденче абзацта «һәм дәвалау-профилактика хезмәте күрсәтү» сүзләрен «хезмәт күрсәтү һәм медицина тәэминаты» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяның алтынчы абзацында «(тикшеренүләре)» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 30 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктында (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5) «махсуслаштырылган сәламәтлек саклау учреждениесендә» сүзләрен «махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмасында» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясындагы 2 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) «дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендәге» сүзләрен «дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларындагы» сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1

ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 2 өлешенең 6 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11; 2007, № 11; 2008, № 6; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) «дәвалау-профилактика учреждениеләренә» сүзләрен «медицина оешмаларына» сүзләренә, «ашыгыч медицина ярдәменә» сүзләрен «кичектергесез яисә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүгә» сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) «сәламәтлек саклауның махсус учреждениесендә» сүзләрен «махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмасында» сүзләренә алмаштырырга.

**7 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендәге «г» пунктчасының өченче абзацында «дәвалау медицина учреждениесеннән» сүзләрен «медицина оешмасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяның «д» пунктында:
а) алтынчы абзацта «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;
б) тугызынчы абзацта «сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләрен «медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга.

**8 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 2 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2) «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга.

**9 статья**

«Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы дүртенче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина һәм мәгариф оешмалары, социаль өлкә, мәдәният, физик культура һәм спорт оешмалары эшчәнлеген үстерү;».

**10 статья**

«Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга.

**11 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $19^3$ статьясындагы 7 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) «сәламәтлек саклау учреждениеләре» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

**12 статья**

«2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

кушымтасының 3 бүлегендәге 3.3 бүлекчәсенең 3.3.2 пунктындагы утыз беренче абзацында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5) «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә, «медицина учреждениесен» сүзләрен «медицина оешмасын» сүзләренә алмаштырырга.

**13 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктта:

«а» пунктчасында «әлеге Законның әлеге статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты һәм 5 статьясындагы 4 пункты нигезендә медицина ярдәме күрсәткәндә» сүзләрен «әлеге Законның әлеге статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты һәм 5 статьясындагы 4, $4^1$ пунктлары нигезендә медицина ярдәме күрсәткәндә, медицина экспертизалары, медицина тикшерүләре һәм медицина таныклаулары үткәргәндә» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «дару препаратлары» сүзләреннән соң «һәм махсуслаштырылган дәвалау-туклану продуктлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^1$ пункт өстәргә:

«$13^1$) гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы кысаларында беренчел медицина-санитария ярдәме алу өчен медицина оешмасын территориаль-участок принцибы буенча сайламаган гражданнарга ашыгыч һәм кичектергесез беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибен билгеләү;»;

2) 5 статьяда:

а) 4 пунктта «Татарстан Республикасы халкына Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буйсынуындагы» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буйсынуындагы медицина оешмаларында ме-

дицина экспертизалары, медицина тикшерүләре һәм медицина таныклаулары үткәрүне оештыру;»;

в) 5 пунктта:

«а» пунктчасында «әлеге Законның әлеге статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты һәм 5 статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты нигезендә медицина ярдәме күрсәткәндә» сүзләрен «әлеге Законның әлеге статьясындагы 1 өлешенең 4, $4^1$ пунктлары һәм 4 статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты нигезендә медицина ярдәме күрсәткәндә, медицина экспертизалары, медицина тикшерүләре һәм медицина таныклаулары үткәргәндә» сүзләренә, «Татарстан Республикасында дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрен» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буйсынуындагы медицина оешмаларын» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «дару препаратлары» сүзләреннән соң «һәм махсуслаштырылган дәвалау-туклану продуктлары» сүзләрен өстәргә;

3) 10 статьяда «федераль медицина учреждениеләрендә» сүзләрен «федераль башкарма хакимият органы буйсынуындагы медицина оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

4) 15 статьяның 2 өлешендә «Наркомания белән авыручы уналты яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаганнар һәм унбиш яшьтән өлкәнрәк башка балигъ булмаганнар» сүзләрен «Наркомания белән авыручы унбиш яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаганнар һәм уналты яшьтән өлкәнрәк башка балигъ булмаганнар» сүзләренә алмаштырырга;

5) 25 статьяда:

а) 2 пунктта «дару препаратлары» сүзләреннән соң «һәм махсуслаштырылган дәвалау-туклану продуктлары» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктта «сәламәтлек саклау учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

6) 28 статьяның 2 өлешендә:

а) 3 пунктта «үтәүгә» сүзен «куллануга» сүзенә алмаштырырга;

б) 4 пунктта «медицина экспертизалары,» сүзләреннән соң «диспансеризация,» сүзен өстәргә.

**14 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 3 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш) «мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф, сәламәтлек саклау оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

**15 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 өлешенең 5 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь) «сәламәтлек саклау учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга.

**16 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 76-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 687. «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 11 (I өлеш), 2 – 23 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

### «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Аксубай муниципаль районы Чистай, Нурлат, Алексеевск, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары белән чиктәш.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Аксубай, Нурлат һәм Чирмешән муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 2,5 км көнчыгышта урнашкан 39 нчы (28 нче) тоташу ноктасыннан алып, Кузайкино – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кабат кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 300 м уза, шуннан соң «Нурлат урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Восход участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м, Кузайкино – Нурлат һәм Аксубай – Федоровка автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,9 км 7, 17, 16, 15 нче урман кварталларының төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,1 км 6 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, көнбатышка таба 300 м, көньякка таба 100 м, аннары 100 м 6 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 6 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м 6 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 50 м буа буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 4,1 км 5 нче, 1 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 1 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 950 м һәм көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 600 м, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м буа буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, кибеп баручы инешне берничә мәртәбә кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 1,1 км 1 нче, 4 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 3,3 км 3 нче, 2 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 2 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге

буйлап көнбатышка таба 150 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 950 м көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км һәм көньяк-көнбатышка таба 500 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,9 км «Нурлат урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чияле Алан участок урманчылыгындагы 7 нче, 6 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба, 700 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Катерга инешенә кадәр уза, шуннан соң әлеге инеш агымы буенча өскә таба 1,0 км бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,8 км 6, 8, 18 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,6 км 17 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 17 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 550 м 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан соң 200 м 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, кабат 150 м 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, 500 м 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,3 км 15, 14, 13 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, көньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 13 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, аннары 150 м 13 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, сынык сызык ясап, 250 м 25 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 2,6 км 24, 12, 5 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 500 м 5 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 150 м 5 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап Зирекле инешенә кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча өскә таба 850 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 850 м көньякка таба 5 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, сынык сызык ясап, 800 м 12 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 900 м 23 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба

50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 950 м 23 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 150 м төньяк-көнчыгышка таба 11 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 1,9 км 11 нче, 4 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,0 км 4 нче, 2 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м 2 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнбатышка таба 1 нче урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 3,0 км 1, 3, 10 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, кибеп баручы инешне берничә мәртәбә кисеп үтеп, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба 21 нче, 20 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң әлеге инеш агымы буенча аска таба 400 м бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 700 м 20 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, 600 м 19 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 19 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 20 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км бара, аннары, Чистай – Аксубай – Нурлат һәм «Чистай – Аксубай – Нурлат» – Иске Мукшы – Кече Сөнчәле автомобиль юлларын тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км Олы Сөлчә елгасына кадәр уза, шуннан соң әлеге елга агымы буенча өскә таба 6,1 км, төньяк-көнбатышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Чистай – Аксубай – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм 350 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң 200 м «Нурлат урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мамык участок урманчылыгындагы 126 нчы

урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 50 м 126 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап һәм төньякка таба 350 м 129 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м һәм көньяк-көнбатышка таба 350 м уза, аннары 100 м 126 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 650 м төньяк-көнбатышка таба 47 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 2,9 км төньякка таба 33, 28, 25 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, сынык сызык ясап, төньякка таба 2,7 км 22 нче, 25 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м 22 нче, 20 нче урман кварталларының төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,3 км 20 нче, 16 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,2 км 16 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, сынык сызык ясап, төньякка таба 250 м 13 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 2,8 км 13, 6, 3 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, 1,8 км 3 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 650 м 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 2 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 900 м 2 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км, төньяк-көнчыгышка таба 350 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кызыл Юл участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 1,1 км шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, шуннан соң инеш агымы буенча өскә таба 150 м, буа буйлап 150 м, инеш агымы буенча кабат өскә таба

900 м бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,5 км әлеге урманчылыктагы 62 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 500 м 62 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 65 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,8 км көнчыгышка таба 65 нче, 66 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,2 км төньяк-көнчыгышка таба 66 нчы, 67 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 400 м төньяк-көнбатышка таба 67 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 100 м 67 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,6 км 67, 66, 64, 61 нче урман кварталларының төньяк, төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, 1,3 км көнчыгышка таба 48 нче, 49 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап,төньяк-көнчыгышка таба 2,1 км 49 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,2 км 44 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,5 км 44 нче, 43 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 3,4 км төньякка таба 43, 37, 32 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 2,6 км төньяк-көнбатышка таба 32 нче, 27 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Шәрбән инешен кисеп үтеп, 100 м 91 нче урман кварталындагы аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 2,0 км 14 нче, 11 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км 11 нче, 15 нче урман кварталларының көньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, көньякка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буй-

лап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км 15 нче, 18 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, сынык сызык ясап, 5,2 км 18, 21, 22, 23 нче урман кварталларының көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап, 350 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м 23 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба 23 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, сынык сызык ясап, 1,0 км көнбатышка таба 23 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 1,0 км 21 нче, 20 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,2 км 20 нче, 17 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньякка таба һәм 300 м төньяк-көнбатышка таба, 17 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, аннары 1,9 км көнбатышка таба 17 нче, 16 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, 100 м 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,9 км көнбатышка таба 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 550 м төньяк-көнбатышка таба 11 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,5 км 7 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 4,2 км көнбатышка таба 7, 6, 5 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 66 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 1,2 км, сынык сызык ясап, 63 нче урман кварталының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 2,4 км төньяк-көнбатышка таба Аксубай, Нурлат һәм Алексеевск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Сосновка авылыннан 5,6 км көньяк-көнбатышка таба урнашкан 8 нче (29 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 8 нче (29 нчы) тоташу ноктасыннан алып

төньякка таба, сынык сызык ясап, 6,6 км «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 62, 49, 31, 30, 21 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 3,9 км 21, 20, 19 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 7,4 км 9, 10, 2, 1 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары, Кече Чирмешән елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 6,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 200 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баганалы участок урманчылыгындагы 150 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м урман утыртмалары буйлап, 100 м «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 73 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман утыртмаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м Кече Чирмешән елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча өскә таба 8,3 км Аксубай, Алексеевск һәм Чистай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Түбән Татар Майнасы авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта Кече Чирмешән елгасы акваториясендә урнашкан X = 394637,75, Y = 1397038,74 координаталы 2 нче (81 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Аксубай, Чистай һәм Яңа Чишмә муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Сидулово-Ерыклы авылыннан 1,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы (80 нче) тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 750 м «Аксубай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чабаксар участок урманчылыгындагы 112 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм көньяк-көнбатышка таба 100 м уза, сынык сызык ясап, 450 м 9 нчы

урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм төньяк-көнбатышка таба 50 м уза, 100 м 9 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 950 м 8 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Зирекле елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча аска таба 1,4 км уза, аннары, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 850 м һәм көньяк-көнбатышка таба 500 м бара, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, Чистай – Аксубай – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 550 м һәм төньяк-көнбатышка таба 400 м уза, 300 м 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 200 м көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 350 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көнбатышка таба куаклык массивы буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м Кече Чирмешән елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча аска таба 11,9 км 2 нче (81 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Аксубай, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Яңа Ибрай авылыннан 1,8 км көнчыгышта урнашкан 35 нче (79 нчы) тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,2 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә һәм, буаны кисеп үтеп, 150 м буа буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 2,0 км, көнбатышка таба 300 м бара, сынык сызык ясап, 4,8 км «Аксубай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ибрай участок урманчылыгындагы

70, 69, 68, 67 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 7,4 км 48, 47, 46, 45, 36, 35 нче урман кварталларының төньяк, төньяк-көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары төньякка таба 1,7 км 35 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, көнбатышка таба 1,6 км 35 нче, 33 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 2,8 км 25 нче, 26 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,2 км көнбатышка таба 26 нчы, 25 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км 22 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, көнбатышка таба 3,9 км 22, 21, 20, 19 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап, төньякка таба 2,1 км 16 нчы, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, Чабаксар елгасын кисеп үтеп, «Аксубай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чабаксар участок урманчылыгындагы 54 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 200 м көнбатышка таба һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап 2,7 км көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 2,9 км 63, 62, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап, көнбатышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 53 нче, 46 нчы урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м урман массивының көньяк чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,0 км 46 нчы, 42 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, сынык сызык ясап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньякка таба 850 м 33 нче, 32 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м 32 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, 300 м 32 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап һәм, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 1,4 км төньяк чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инеш-

не кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 21 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м 7 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, 150 м 7 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, 50 м урман массивының көньяк чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км 12 нче, 11 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 10 нчы (80 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы (28 нче) тоташу ноктасыннан алып, Кузайкино – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 5,0 км Олы Сөлчә елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча өскә таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 3,1 км, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,5 км кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,9 км Сөлчә елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча өскә таба 350 м шушы елгага коя торган инеш тамагына кадәр уза, 2,3 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба буага кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба 150 м буа буйлап, инеш агымы буенча өскә таба 250 м буа плотинасына кадәр уза, 40 м буа плотинасының көньяк, көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, шуннан соң буаның уң яры буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м Кәләй инеше тамагына кадәр уза, әлеге инешнең агымы буенча өскә таба 30 м бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 650 м, төньяк-көнбатышка таба 100 м уза, сынык сызык ясап, 250 м «Чирмешән урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Светлогорск участок урманчылыгындагы 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 72 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, үләт базының көньяк чиге

буйлап 30 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, төньякка таба 1,8 км 72 нче, 65 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 1,5 км һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,3 км бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,2 км 64 нче, 39 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, «Аксубай – Федоровка» – Яңа Ибрай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 39 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,9 км һәм, сынык сызык ясап, «Аксубай – Федоровка» – Яңа Ибрай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кабат кисеп үтеп, төньяк чиге буйлап 2,7 км көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м 39 нчы, 40 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м бара, 300 м 40 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, 400 м 40 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, 1,5 км 40 нчы, 50 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көнчыгышка таба 350 м 51 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көнчыгышка таба 100 м 51 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, куаклык массивының көньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 50 м куаклык массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, 100 м 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, 500 м 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм 400 м 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 29 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,2 км һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 800 м, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 50 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 1,5 км 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң, кибеп баручы инеш-

не кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 2,7 км 30 нчы, 31 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, Кәләй инешен кисеп үтеп, 950 м 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км 32 нче урман кварталының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, буаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 32 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, 1,8 км 33 нче, 23 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 850 м 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 100 м 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м 16 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, 50 м 16 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 250 м 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 350 м 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, сынык сызык ясап, 450 м 16 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, төньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Яңа Ибрай авылын һәм Рус Волчья Бистәсен тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 35 нче (79 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта

## Аксубай муниципаль районының «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Кәкрекүл, Яңа Аксубай, Яңа Кармәт, Иске Илтерәк һәм Иске Кармәт авыл җирлекләре белән чиктәш.

«Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Иске Кармәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Иске Кармәт һәм Яңа Кармәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кармәте авылыннан 1,6 км көнчыгышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м калкулыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, 950 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, Чистай – Аксубай – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 20 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м куаклык полосасының

көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Иске Кармәт һәм Иске Илтерәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Кармәт авылыннан 2,2 км көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Иске Илтерәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 4,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Чистай – Аксубай – Нурлат» – Чуаш Енорускиносы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл кырыендагы урман полосасын кисеп үтеп, Кече Сөлчә елгасына кадәр уза, 1,5 км бу елга агымы буенча аска таба «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Иске Илтерәк һәм Яңа Аксубай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Киса авылыннан 750 м төньякта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Яңа Аксубай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып Кече Сөлчә елгасы агымы буенча аска таба 5,2 км бу елгага инеш койган җиргә кадәр уза, 250 м бу инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба 800 м әлеге автомобиль юлы буйлап бара, Аксубай – Федоровка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 20 м уза һәм 50 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 750 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м җитештерү объектының көнбатыш чиге буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Яңа Аксубай һәм Кәкрекүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Аксубай авылыннан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Кәкрекүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Аксубай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Аксубай участок урманчылыгындагы 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 2,8 км профильле башка автомобиль юлы буйлап уза, 100 м сәнәгать объектының

көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Кече Сөлчә елгасына кадәр бара, 2,1 км әлеге елга агымы буенча аска таба уза, аннары, кибеп баручы инешне һәм Чистай – Аксубай – Нурлат автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 950 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,7 км «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Кәкрекүл һәм Яңа Кармәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Кармәт авылыннан 3,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Яңа Кармәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, 100 м «Аксубай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Аксубай участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,8 км 4 нче, 2 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 350 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 1,9 км «Аксубай – Емелькино» – Яңа Кармәт автомобиль юлына кадәр бара, төньяк-көнчыгышка таба шушы автомобиль юлы буйлап 1,4 км Аксубай – Емелькино автомобиль юлына кадәр уза, көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 20 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,2 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км, төньяк-көнбатышка таба 350 м, көньяк-көнчыгышка таба 700 м, төньяк-көнбатышка таба 950 м, көньяк-көнчыгышка таба 950 м, төньяк-көнбатышка таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 350 м, көньяк-көнбатышка таба 850 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км кибеп баручы инешкә кадәр бара, 950 м әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 2,1 км, төньяк-көнбатышка таба 300 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км, көньяк-көнбатышка таба 1,7 км, төньяк-көнбатышка таба 800 м, төньяк-көнчыгышка таба 800 м, төньяк-көнбатышка таба 550 м, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км, төньяк-көнбатышка таба 400 м, көньяк-көнчыгышка таба 450 м 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 4 нче кушымта

## Аксубай муниципаль районының «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Беловка авыл җирлеге Иске Кыязлы, Иске Тимошкино, Иске Үзи авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы белән чиктәш.

Беловка авыл җирлеге чиге Иске Тимошкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Беловка, Иске Тимошкино һәм Иске Үзи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Медянка авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км «Аксубай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Аксубай участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 350 м көньяк-көнбатышка таба көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньякка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы Кәчинкә инешенә кадәр бара, 2,1 км әлеге инеш агымы буенча аска таба Олы Сөлчә елгасына койган җиргә кадәр уза, 650 м бу елга агымы буенча өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м, «Аксубай – Федоровка» – Иске Үзи автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньякка таба 850 м уза, 50 м җитештерү объектының көнчыгыш чиге буйлап, инешнең уң яктагы текә ярын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 2,0 км әлеге инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң, Аксубай – Федоровка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буендагы урман полосаларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км, көнчыгышка таба 2,0 км бара, урман полосасының көньяк чиге буйлап 200 м Беловка, Иске Тимошкино һәм Иске Кыязлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сергеевский поселогыннан 2,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Беловка авыл җирлеге чиге Иске Кыязлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Беловка, Иске Кыязлы авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сергеевский поселогыннан 1,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Беловка авыл җирлеге чиге Нурлат муниципаль районы белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып Аксубай муниципаль районы чиге буйлап Беловка, Иске Үзи авыл җирлекләре һәм Нурлат муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Үзи авылыннан 2,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Беловка авыл җирлеге чиге Иске Үзи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 1,3 км, «Аксубай – Федоровка» – Иске Үзи автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,8 км уза, 100 м сазлык буйлап бара, Олы Сөлчә елгасын һәм текә ярны кисеп үтеп, кабат авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м уза, шуннан соң төньякка таба 300 м, төньяк-көнбатышка таба 2,2 км, төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км бара, аннары төньяк-көнбатышка таба «Аксубай урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Аксубай участок урманчылыгындагы 52 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 3,7 км 52, 51, 50 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 5 нче кушымта

## Аксубай муниципаль районының «Емелькино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Емелькино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Емелькино авыл җирлеге Яңа Кармәт, Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Нурлат муниципаль районнары белән чиктәш.

Емелькино авыл җирлеге чиге Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Емелькино, Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Емелькино авылыннан 3,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, куаклык полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м һәм 250 м көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, куаклык полосасын кисеп үтеп, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, профильле автомобиль юлына һәм Емелькино – Иске Татар Әдәмсуы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,1 км, Адәмсу елгасын һәм аның текә ярларын, буаны һәм кибеп баручы инешләрне берничә мәртәбә кисеп үтеп, көньякка таба 500 м, кибеп баручы инешне ике мәртәбә кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 500 м уза, 650 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, «Биләр урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биләр участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш

чиге буйлап 750 м һәм көньяк-көнбатышка таба 400 м көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 2,2 км 7 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 2,0 км 7 нче, 14 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап Емелькино, Иске Татар Әдәмсуы һәм Яңа Кармәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сосновка авылыннан 3,3 км көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кышлау авыл җирлеге чиге Өҗем авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, аннары, сынык сызык ясап, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 8,1 км, Кышлау — Кызыл Утар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м, төньяк-көнчыгышка таба 900 м, көньяк-көнчыгышка таба 30 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м, чокырны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 200 м, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м уза, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,4 км, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км, көньяк-көнбатышка таба 900 м, төньяк-көнчыгышка таба 600 м, көньяк-көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң Кышлау — Кызыл Утар автомобиль юлы буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м уза, аннары,

сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,0 км, Түбән Өҗем – Ташчишмә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Кышлау, Өҗем авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Өҗем авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кышлау авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып Әтнә муниципаль районы чиге буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 11 нче кушымта

## Әтнә муниципаль районының «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Әтнә, Комыргуҗа, Күәм, Түбән Көек авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге чиге Түбән Көек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Бәрәскә, Түбән Көек авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Атамыш авылыннан 850 м көньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып Ашыт елгасы агымы буенча өскә таба 16,3 км Түбән Бәрәскә, Түбән Көек һәм Күәм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Көек авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге чиге Күәм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Бәрәскә, Күәм һәм Олы Әтнә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күәм авылыннан 1,6 км

көньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Ашыт елгасы агымы буенча аска таба 7,5 км 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге чиге Олы Әтнә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Бәрәскә, Олы Әтнә һәм Комыргуҗа авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мәрҗән авылыннан 2,3 км төньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,0 км, көньяк-көнбатышка таба 450 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 400 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, урман полосасы буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасы буенча 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, чокырны ике мәртәбә кисеп үтеп, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,2 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 450 м, төньяк-көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр 900 м уза, шуннан соң аның агымы буенча аска таба Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосага кадәр 1,4 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 500 м, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр 300 м уза, аның агымы буенча аска таба 1,7 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, сазлык буйлап 1,2 км, канауны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге чиге Комыргуҗа авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, аннары чокыр төбе буйлап көньяк-көнбатышка таба 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 600 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр 50 м уза, аның агымы буенча аска таба шушы инешкә икенче кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр 750 м бара, шуннан соң аның агымы буенча өскә таба 1,3 км Түбән Бәрәскә, Комыргуҗа авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Мәрҗән авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге чиге Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып Әтнә муниципаль районы чиге буйлап 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 12 нче кушымта

## Әтнә муниципаль районының «Түбән Көек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Түбән Көек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Түбән Көек авыл җирлеге Күәм, Күлле Киме, Түбән Бәрәскә авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы белән чиктәш.

Түбән Көек авыл җирлеге чиге Күлле Киме авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Көек, Күлле Киме авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ары авылыннан 3,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып «Ары урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Илет участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 650 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 50 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 1,2 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 250 м һәм көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м бара, алга таба 50 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м бара, 93 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча төньяк-көнчыгышка таба 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, сынык сызык ясап, 93 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 650 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м, 93 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча, берничә мәртәбә кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 450 м, Күлле Киме – Ары автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм ике мәртәбә кибеп баручы

инешне, аның текә ярларын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 300 м, көньяк-көнчыгышка таба 350 м, яңадан Күлле Киме – Ары автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 500 м, Күлле Киме – Ары автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнчыгышка таба, яңадан Күлле Киме – Ары автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,3 км бара, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр 100 м бара, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба аның буага коя торган җиренә кадәр 3,0 км уза, буа буйлап көньяк-көнчыгышка таба 800 м бара, алга таба инеш агымы буенча аска таба, Олы Әтнә – Күлле Киме автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,7 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, торф чыгару урыннары буенча 200 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м Түбән Көек, Күлле Киме һәм Күәм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каенсар авылыннан 100 м көнбатышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Көек авыл җирлеге чиге Күәм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Көек, Күәм һәм Түбән Бәрәскә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Көек авылыннан 1,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасыннан алып, Олы Әтнә – Күлле Киме автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Үртәм елгасы агымы буенча өскә таба 4,9 км уза, шуннан соң буа буйлап төньякка таба 350 м 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Түбән Көек авыл җирлеге чиге Түбән Бәрәскә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Көек, Түбән Бәрәскә авыл җирлекләре һәм Биектау муниципаль районы чикләре тоташкан урында Атамыш авылыннан 850 м көньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып Ашыт елгасы агымы буенча өскә таба 16,3 км 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Түбән Көек авыл җирлеге чиге Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып Әтнә муниципаль районы чиге буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 13 нче кушымта

## Әтнә муниципаль районының «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Шашы авыл җирлеге Күәм, Күңгәр, Кышлау авыл җирлекләре, Арча муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы белән чиктәш.

Яңа Шашы авыл җирлеге чиге Күңгәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Шашы, Күңгәр һәм Күәм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Җогып авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының көньяк чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2,1 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км, кибеп баручы инешне һәм чокырны кисеп үтеп, урман полосасының төньяк чиге буйлап 100 м, урман полосасы буенча 200 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м Яңа Шашы, Күңгәр һәм Кышлау авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кышлау авылыннан 150 м көнбатышта Шашы елгасы үзәнендә урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Шашы авыл җирлеге чиге Күәм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Шашы, Күәм авыл җирлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Иске Җогып авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 1,5 км 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Шашы авыл җирлеге чиге Марий Эл Республикасы белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Яңа Шашы авыл җирлеге, Арча муниципаль районы һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Мамыш авылыннан 4,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче (12 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Шашы авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 11 нче (12 нче) тоташу ноктасыннан алып Әтнә муниципаль районы чиге буйлап Яңа Шашы, Кышлау авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кызыл Утар авылыннан 4,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Шашы авыл җирлеге чиге Кышлау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча аска таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр 1,4 км уза, аннары шушы кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,1 км бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, урман массивының төньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр 40 м бара, шушы инеш агымы буенча өскә таба 800 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 450 м, көньяк-көнбатышка таба 250 м уза, алга таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км, «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 56 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, чокыр төбе буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 56 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, чокыр төбе буенча инешкә кадәр 100 м, шушы инеш агымы буенча аска таба аның Шашы елгасына койган җиренә кадәр, Күшәр – Ключи-Сап автомобиль юлын кисеп үтеп, 4,6 км бара, шуннан соң Шашы елгасы агымы буенча аска таба 2,5 км 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 14 нче кушымта

## Әтнә муниципаль районының «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Өҗем авыл җирлеге Күңгәр, Кышлау авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы белән чиктәш.

Өҗем авыл җирлеге чиге Күңгәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Өҗем, Күңгәр авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Мокшы авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, «Арча урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тукай участок урманчылыгындагы 45 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 45 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 800 м уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км, Олы Әтнә – Ташкичү автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, канау буйлап 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, канауны һәм куаклык массивын кисеп үтеп, Ашыт елгасына кадәр 300 м бара, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 1,7 км, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 300 м Өҗем, Күңгәр һәм Кышлау авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Өҗем авылыннан 1,7 км көньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Өҗем авыл җирлеге чиге Кышлау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, аннары, сынык сызык ясап, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 8,1 км, Кышлау – Кызыл Утар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м, төньяк-көнчыгышка таба 900 м, көньяк-көнчыгышка таба 30 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м, чокырны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 200 м, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м уза, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,4 км, төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км, көньяк-көнбатышка таба 900 м, төньяк-көнчыгышка таба 600 м, көньяк-көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң Кышлау – Кызыл Утар автомобиль юлы буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,0 км, Түбән Өҗем – Ташчишмә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Өҗем, Кышлау авыл җирлекләре һәм Арча муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Өҗем авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Өҗем авыл җирлеге чиге Арча муниципаль районы белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып Әтнә муниципаль районы чиге буйлап 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 24 июле
№ 78-ТРЗ

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 689. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле өченче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының илле өченче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 627-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

3. «Татарстан Республикасында географик объектлар атамалары өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 598-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

4. «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 591-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында» 607-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

6. «Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^1$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 613-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

7. «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 614-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 615-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 651-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 634-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 647-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 646-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуларын тану турында» 631-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 654-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 650-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 645-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) кучемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 624-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 628-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 625-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

20. «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 630-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

21. «Пенсиягә федераль социаль өстәмә күләмен билгеләү өчен 2015 елга Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы күләмен билгеләү хакында» 632-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

22. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 633-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

23. «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 648-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

24. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 626-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

25. «2014 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның

дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 649-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

26. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында.

27. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Татарстан – яңа гасыр» депутат группасының 2009 – 2014 еллардагы эшчәнлеге турында хисап.

28. Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе эшчәнлеге турында хисап.

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

31. «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 516704-6 номерлы федераль закон проекты турында (тиешле территорияләрдә Федераль миграция хезмәте бүлекчәләре булмаган очракта Россия Федерациясе гражданнарын тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбен гамәлгә ашыруга җирле үзидарә органнарының хокукын күрсәтү өлешендә).

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 527750-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе континенталь шельфында урнашкан ясалма утраулар, җайланмалар һәм корылмалар тирәсендә урнаштырылган иминлек зоналарында суднолар йөреше иминлеген тәэмин итү буенча таләпләрне бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына фотога, кинога һәм видеога төшерү, тавыш яздыру материалларын административ хокук бозу хакындагы эш буенча дәлилләргә кертү бурычы өлешендә үзгәреш кертү хакында» 492044-6 номерлы федераль закон проекты турында.

34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 525742-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодекстагы 19.7 статьяның диспозициясен төгәлләштерү өлешендә).

35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.22 статьясына үзгәреш кертү хакында» 528878-6 номерлы федераль закон проекты турында (күпфатирлы йортларда торак булмаган урыннарны законсыз рәвештә яңадан төзү һәм яңадан планировкалау өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

36. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

37. «Парламент контроле турында» Федераль законның 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Саха Республикасы (Якутия) Дәүләт Собраниесенең (Ил Тумэн) закон чыгару инициативасы турында.

38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.8 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

39. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

40. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 30.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Әстерхан өлкәсе Думасының закон чыгару инициативасы турында.

41. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 538049-6 номерлы федераль закон проекты хакында («Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» Федераль законга кертелә торган үзгәрешләргә бәйле рәвештә).

42. «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә архив эше турында» Федераль законның 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проек-

тын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

43. «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 26 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ненец автономияле округы депутатлары Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

44. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.3 статьясына һәм «Россия Федерациясендә архив эше хакында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

45. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

46. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлауларда сәяси партияләрнең, сайлау берләшмәләренең, кандидатларның финанс хисаплылыгы мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү турында» 545825-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

47. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның $14^1$ һәм $16^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 502311-6 номерлы федераль закон проекты турында (җирле үзидарә органнарының хуҗасыз хайваннарны аулау һәм тоту хокуклары хакында).

48. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясындагы 6 пунктына үзгәреш кертү хакында» 516707-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының җирле үзидарә органнарына бирелергә мөмкин аерым дәүләт вәкаләтләрен ачыклау өлешендә).

49. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакын-

да» 514164-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль хезмәткә кергәндә конкурс үткәрүнең мәҗбүрилеген билгеләү өлешендә).

50. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 528411-6 номерлы федераль закон проекты турында (җирле үзидарә оештыруның кайбер гомуми принципларын ачыклау өлешендә).

51. «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 81 һәм 83 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 61045-6 номерлы федераль закон проекты хакында (балаларның алиментлар алу хокукларына гарантияләрне көчәйтү максатларында).

52. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законның 53.4 статьясына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 527276-6 номерлы федераль закон проекты турында («Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 20 статьясына туры китерү өлешендә).

53. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 18 статьясына үзгәреш кертү хакында» 520973-6 номерлы федераль закон проекты турында.

54. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $195^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 537948-6 номерлы федераль закон проекты турында (эш бирүчеләрнең һөнәри стандартларны кулланырга тиешлеген законнар белән ныгыту өлешендә).

55. «Хезмәт пенсиясенең тупланма өлешенә өстәмә иминият кертемнәре һәм пенсия тупланмаларын булдыруга дәүләт ярдәме турында» һәм «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәптә тору турында» федераль законнарга үзгәрешләр кертү хакында» 537967-6 номерлы федераль закон проекты турында (ихтыярый пенсия тупланмаларын дәүләт финанслашуы программасына иминләштерелгән затларның керү вакытын озайту хакында).

56. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына фәнни хезмәткәрләр, фәнни оешмалар җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары хезмәтен җайга салу механизмнарын камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 540253-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

57. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 539568-6 номерлы федераль закон проекты турында («археология предметы» төшенчәсен билгеләүне үзгәртү өлешендә).

58. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 540884-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль хезмәткә бәйле өстәмә чикләүләр билгеләү өлешендә).

59. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 534999-6 номерлы федераль закон проекты турында (федераль законның аерым нигезләмәләрен камилләштерү өлешендә).

60. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм «Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 544657-6 номерлы федераль закон проекты турында (архитектура проектын төзүгә бәйле аерым нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә).

61. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 һәм $55^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 526156-6 номерлы федераль закон проекты хакында (капиталь төзелеш объектларының иминлегенә тәэсир итә торган эшләргә рөхсәт бирү таныклыкларын бирүгә минималь кирәкле таләпләрне төгәлләштерү өлешендә).

62. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 526013-6 номерлы федераль закон проекты турында (биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгын арттыру максатларында аерым нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә).

63. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 514465-6 номерлы федераль закон проекты турында (товарларны маркировкалауга таләпләр билгеләү һәм аларны бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).

64. «Күңел ачу хезмәтләре күрсәткәндә музыкаль әсәрләрне башкаручыларның фонограммадан файдалануы турында кулланучыларга мәгълүмат бирүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 299577-6 номерлы федераль закон проекты турында.

65. «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 555597-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

66. «Дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләре башкарганда артык таләпләрне бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 543486-6 номерлы федераль закон проекты турында.

67. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясының 2 өлешендәге 4 пунктына

үзгәреш кертү хакында» 524685-6 номерлы федераль закон проекты турында (коммерцияле булмаган оешмалар, шул исәптән халыкара оешмаларның һәм чит илләрнең коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының структур бүлекчәләре, иҗтимагый берләшмәләр, сәяси партияләр һәм дини оешмалар эшчәнлеген тикшереп тору (күзәтчелек итү) өлкәсендә функцияләр башкаруга вәкаләтле органнарның вазыйфаи затларының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен ачыклау өлешендә).

68. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына легаль булмаган миграцияне булдырмау максатларында үзгәрешләр кертү турында» 537130-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар катнашында миграция мөнәсәбәтләрен җайга салуны камилләштерү буенча кайбер чараларны гамәлгә ашыру максатларында).

69. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 541189-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чарасы хәрәкәт итүнең сәгатенә 60 километрдан артык итеп билгеләнгән тизлеген сәгатенә 10 километрдан күбрәккә арттырган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

70. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар кайбер хокук бозуларны кылган очракта аларны Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрү тиешлеген билгеләүче үзгәрешләр кертү хакында» 544880-6 номерлы федераль закон проекты турында (чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан хокук бозулар кылынган очракта аларны Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрү карала торган административ хокук бозулар исемлеген ачыклау өлешендә).

71. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше йомгаклары турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3656-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 690. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Әлмәт суд районы буенча:
6 нчы суд участогына – Аблакова Флера Равил кызын;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
10 нчы суд участогына – Мазина Наталья Николаевнаны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Яһудина Раилә Равил кызын;
7 нче суд участогына – Гафурова Гөлнара Александровнаны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Кузнецов Владимир Николаевичны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Мельникова Ольга Васильевнаны.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Аблакова Флера Равил кызының, Мазина Наталья Николаевнаның, Гафурова Гөлнара Александровнаның һәм Мельникова Ольга Васильевнаның Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры аларның моннан алдагы вәкаләтләре чоры тәмамланган көннән башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре
2014 елның 8 июле
№ 3657-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 691. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 15 гыйнварындагы 4648-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1) үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3658-IV ДС

2014 елның 8 июлендәге
3658-IV ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
кушымта

## Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләренең киңәшмәсе турында НИГЕЗЛӘМӘ

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре киңәшмәсе (алга таба – вәкилләр киңәшмәсе), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе сайланганнан соң, бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының (алга таба – Дәүләт Советы) беренче утырышы каравына чыгарыла торган мәсьәләләр турында алдан фикер алышу өчен дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан чакырыла.

2. Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре түбәндәгечә сайлана:

1) бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган Дәүләт Советы депутатларының территориаль җыелышларында;

2) депутатлыкка кандидатларның республика исемлекләре буенча сайланган Дәүләт Советы депутатлары җыелышларында.

3. Дәүләт Советы депутатлары җыелышлары (алга таба шулай ук – депутатлар җыелышлары) сайлауларның гомуми нәтиҗәләре билгеләнгән көннән алып 5 көннән дә соңга калмыйча уздырыла.

4. Дәүләт Советы депутатларының территориаль җыелышлары түбәндәгечә уздырыла:

1) 1 нче – 16 нчы бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Казан шәһәрендә;

2) 17 – 23, 37, 42 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Чаллы шәһәрендә;

3) 24 – 26, 34, 35, 38, 43, 44 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Түбән Кама шәһәрендә;

4) 27 – 29, 32, 33, 36, 39, 40 нчы бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Әлмәт шәһәрендә;

5) 30, 31, 41, 45 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Зеленодольск шәһәрендә;

6) 46 нчы – 50 нче бермандатлы округлар буенча сайланган депутатлар өчен Лаеш шәһәрендә.

5. Дәүләт Советы депутатлары вәкилләре вәкилләр киңәшмәсенә түбәндәге вәкиллек нормасыннан чыгып сайланалар: өч депутаттан бер вәкил, кандидатларның республика исемлеге буенча сайланган депутатлар саны өчтән ким булган очракта, – кандидатларның тиешле республика исемлегеннән бер вәкил. Дәүләт Советы депутатлары вәкилләрен сайлау турында депутатлар җыелышының беркетмәсе төзелә.

6. Бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган Дәүләт Советы депутатларының территориаль җыелышларын, шулай ук вәкилләр киңәшмәсенең беренче утырышын яше буенча иң өлкән Дәүләт Советы депутаты ача һәм алып бара.

7. Вәкилләр киңәшмәсенең беренче утырышында Дәүләт Советының 11 – 13 депутаты составында вәкилләр киңәшмәсенең оештыру комитеты төзелә. Вәкилләр киңәшмәсенең оештыру комитеты рәистән, секретарьдан һәм вәкилләр киңәшмәсенең беренче утырышында сайлана торган оештыру комитеты әгъзаларыннан гыйбарәт була.

8. Вәкилләр киңәшмәсенең оештыру комитеты түбәндәге мәсьәләләрне әзерли:

1) Дәүләт Советының беренче утырышы каравына чыгарыла торган, шул исәптән аны оештыру турындагы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне;

2) Дәүләт Советының беренче утырышы эше тәртибе буенча тәкъдимнәрне;

3) Дәүләт Советының беренче утырышының эшче органнары турында түбәндәге тәкъдимнәрне:

яшерен тавыш бирүне уздыру өчен хисап комиссиясенең санлы һәм персональ составы турында;

Дәүләт Советы сессиясе секретариатының санлы һәм персональ составы турында;

редакция комиссиясенең санлы һәм персональ составы турында;

Дәүләт Советы регламент төркеменең санлы һәм персональ составы турында;

электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясенең санлы һәм персональ составы турында;

4) Дәүләт Советының беренче утырышын трансляцияләү режимы турындагы тәкъдимнәрне;

5) Дәүләт Советы Рәисе кандидатурасы буенча тәкъдимнәрне;

6) Дәүләт Советы комитетларын төзү һәм аларның әгъзаларын сайлау турындагы тәкъдимнәрне.

9. Вәкилләр киңәшмәсенең оештыру комитеты рәисе түбәндәгеләрне башкара:

вәкилләр киңәшмәсенең икенче һәм аннан соңгы утырышларын алып бара;

оештыру комитеты утырышын чакыра һәм алып бара;

Дәүләт Советының беренче утырышында вәкилләр киңәшмәсе кертә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясый.

10. Вәкилләр киңәшмәсе һәм аның оештыру комитеты утырышы, әгәр киңәшмәдә Дәүләт Советы депутатларының сайланган вәкилләреннән кимендә өчтән икесе катнашса, ә оештыру комитеты утырышында комитетның билгеләнгән санлы составыннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була.

11. Вәкилләр киңәшмәсе карарлары вәкилләр киңәшмәсенә сайланган Дәүләт Советы депутатларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

12. Оештыру комитеты карарлары комитетның билгеләнгән санлы составыннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

13. Вәкилләр киңәшмәсе һәм оештыру комитеты утырышларында беркетмәләр алып барыла, аларга оештыру комитеты рәисе һәм секретаре имза куя.

14. Дәүләт Советының беренче утырышы өчен документлар вәкилләр киңәшмәсе каравына оештыру комитеты тарафыннан кертелә. Вәкилләр киңәшмәсендә доклад белән оештыру комитеты рәисе чыгыш ясый.

15. Вәкилләр киңәшмәсендә кабул ителгән документлар Дәүләт Советы каравына кертелә.

16. Депутатлар җыелышлары, вәкилләр киңәшмәсе һәм аның оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру-хокукый тәэмин итүне Дәүләт Советы Аппараты гамәлгә ашыра.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 692. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 627-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 627-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 8 июленә 11 сәгать 30 минутка кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 8 июленә 12 сәгатькә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3659-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 693. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 627-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 627-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3660-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 694. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (627-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (627-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3661-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 695. «Татарстан Республикасында географик объектлар атамалары өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 598-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасында географик объектлар атамалары өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 598-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3662-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 696. «Татарстан Республикасында географик объектлар атамалары өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы законы хакында (598-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында географик объектлар атамалары өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы законын (598-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3663-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 697. «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 591-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 591-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3664-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 698. «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (591-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (591-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 8 июле
№ 3665-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 699. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында» 607-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында» 607-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

